ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ
КАРШЫНДАГЫ ЭШКУАРЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ
ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ КАРШЫНДАГЫ ЭШКУАРЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ 2013 ЕЛДА ЭШЧӘНЛЕГЕ ЙОМГАКЛАРЫ ҺӘМ 2014 ЕЛГА БУРЫЧЛАР ТУРЫНДА

Казан шәһәре
2014 ел

**ЭЧТӘЛЕК:**


**Битләр**

**I.** Кереш 88

**II.** Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты 91

**III.** Эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләрен анализлау 108

**IV.** Ирешелгән уңышлар 120

**V.** Системалы мәсьәләләр 132

**VI.** Амнистия 149

**VII.** Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеген алып бару шартларына бәяләмә 153

**VIII.** Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукый хәлен камилләштерү буенча тәкъдимнәр 162

**IX.** 2014 елга бурычлар 168

## КЕРЕШ

Эшкуарлык икътисад өлкәсендә нәтиҗәле эш алып баруның нигезен тәшкил итә.

Эшкуарлыкның уңышлы үсүе урта сыйныфны формалаштыру, инновацияле икътисадка күчүне тәэмин итү, чималга нигезләнмәгән икътисадка күчү өчен шартлар тудыру һәм башка шундый күп кенә бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Бүген эшкуарлыкны үстерү буенча дәүләт сәясәте кысаларында бизнесны җайга салу мохитен яхшыртуга, салымнар өлкәсендә идарә итүне, монополиягә каршы сәясәтне, хезмәт турындагы законнарны камилләштерүгә, инвесторлар хокукларын яклауга һәм башка мәсьәләләргә юнәлтелгән күп кенә чаралар тормышка ашырыла.

Икътисад өлкәсендә яңа кыенлыклар туа барган саен, банк кредитларыннан күпләр файдалана алуны һәм дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, инфраструктурадан, дәүләт заказларыннан һәм муниципаль заказлардан файдалануны киңәйтү һ.б. – эшкуарлык үсешендә мөһим юнәлешләргә әверелә бара.

Шуның белән бергә, эшкуарларның дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнары белән хезмәттәшлегендә уңай эшлекле климат һәм нәтиҗәле элемтәләр булдыру, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау төп бурыч булып тора.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләтнең икътисад өлкәсендә озак вакытка исәпләнгән сәясәте» 2012 елның 7 маендагы 596 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясендә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты булдырылды. 2012 елның июнендә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасы кертелде.

Әлеге институтны булдыру зарурияте эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының аларның хокуклары бозылу һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлмәү очракларында һәрвакытта да кыенлыкларны үзләре генә хәл итә алмавы белән бәйле. Әлеге институтның эшчәнлеге дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнары һәм аларның вазыйфаи затлары

тарафыннан административ киртәләр корылганда, бюрократик басым ясалганда, коррупциячел гамәлләр кылынганда аеруча кирәк була.

Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары тарафыннан үз хокукларын яклауны һәм ирекле рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итүче өстәмә гарантия булып тора, шулай ук эшкуарларның дәүләт белән үзара хезмәттәшлегендә юл күрсәтүче ролен үти.

Киң мәгънәсендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты бизнес үсеше юлында барлыкка килгән системалы проблемаларны хәл итүгә эшкуарлар һәм экспертлар берләшмәләрен, дәүләт институтларын һәм иҗтимагый институтларны җәлеп итүгә нигезләнгән гамәлдәге дәүләт сәясәте элементы, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокуклары бозылу һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлмәү очракларыннан турыдан-туры саклану коралы булып тора.

Эшкуарларның бүгенге көндә берникадәр хәл ителмәгән хосусый, шулай ук системалы мәсьәләләре барлыгы эш барышында ачыкланды.

Аларны эзлекле рәвештә хәл итү уздырыла торган дәүләт сәясәте нәтиҗәлелеген күтәрергә, эшкуарлык эшчәнлеге барышында килеп чыгуы мөмкин булган төрле куркынычларны киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан халыкара тәҗрибәгә кыскача күзәтү ясалган чыгыш әзерләнде, аерым бер бүлектә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча федераль һәм республика вәкаләтле вәкилләренең вәкаләтләре һәм институт мохите тасвирлана, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил адресына 2013 елда кергән мөрәҗәгатьләргә аналитик күзәтү һәм аларны тикшерү йомгаклары, системалы мәсьәләләргә күзәтү китерелә.

Әлеге чыгыш «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 05 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясын үтәү яктылыгында әзерләнде. Аның нигезендә календарь ел тәмамланганнан соң, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, шулай ук Россия

Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларын бәяләп,  эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәр белән үз эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында мәгълүмат җибәрә.

## ЭШКУАРЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ИНСТИТУТЫ

### ДӨНЬЯДА ТУПЛАНГАН ТӘҖРИБӘГӘ КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ

Омбудсмен институты классик мәгънәсендә низагларны хәл итү институты булып тора. Аның тарихы Скандинавия илләре хокукый һәм сәяси-административ системаларыннан башлана. 1990 еллар уртасыннан омбудсмен институтының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итүгә юнәлтелгән стандартлар һәм тәкъдимнәр БМО («Париж принциплары») һәм Европа Советының Венеция комиссиясе тарафыннан эшләнде. Гражданнарны намуссыз идарәдән[1], ягъни мәсәлән хөкүмәт һәм дәүләт администрациясе тарафыннан кулланылган чараларга каршы аерым кешенең хокукларын яклау – омбудсменның төп максаты. Омбудсмен физик яисә юридик ике зат арасындагы бәхәсләрне хәл итми.

Хәзерге вакытта дөньяның күп кенә илләрендә бизнес-омбудсмен институты эшли. Россия Федерациясендә – бу Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил.

Төрле илләрдә бизнес омбудсменнарның вәкаләтләре төрлечә була. Тәгаен бер илгә хас үзенчәлекләр бизнес-омбудсмен институтының хокукый һәм административ нигезләрен һәм статусын билгелиләр.

Төп хөкүмәт оешмалары тарафыннан намуссыз идарәгә каршы эшкуарлар мәнфәгатьләрен яклау өчен хөкүмәт башлангычы белән махсус булдырылган институтлар түбәндәге илләрдә бар:

**АКШ**: 1996 елда Кече бизнес администрациясе каршындагы Милли омбудсмен аппараты (хөкүмәт органы);

АКШта Кече бизнес өчен милли омбудсмен вазыйфасы кирәгеннән артык административ чаралардан кече бизнесны яклау буенча законнарның нәтиҗәле эшләвен тикшергәннән соң кертелде. 1980 елгы сизгерлек күрсәтеп җайга салу турындагы Закон федераль агентлыклардан җайга салуның кече бизнеска йогынтысын исәпкә алуны таләп итә. Дәүләт

[1] Кара., мәсәлән.: Doc. 13236, 2013елның 21 июне, Европада омбудсмен институтын ныгыту, Парламент ассамблеясенә Хокукый мәсьәләләр һәм кеше хокуклары комитеты доклады. Докладчы: Жорди ХУКЛА, Испания; http://www.assembly.coe.int/nw/xml/XRef/X2H-Xref-ViewPDF.asp?FileID=19786&lang=en

органнары кече бизнеска басым тигез бүленсен өчен, җайга салуны ничегрәк гамәлгә ашыруны, мөмкин кадәр, исәпкә алырга тиешләр. 1996 елның мартында АКШ Конгрессы сизгерлек күрсәтеп җайга салу турындагы Законны кече бизнеста хокукый актларны дөрес куллану турында Закон чыгару юлы белән көчәйтте. Закон федераль агентлыклар тарафыннан законнарны үтәмәгән өчен административ җәзаларны киметүче яисә хәтта юкка чыгаручы сәясәт яисә программа эшләүне күздә тота. Милли омбудсмен институты кече бизнеста хокукый актларны дөрес куллану турындагы төбәк советлары белән берлектә дәүләт органнары белән кече бизнес арасындагы низагларны хәл итү өчен гамәлгә куелды. АКШта Милли омбудсменың төп бурычы булып, АКШ икътисадының аеруча мөһим секторы буларак, кече бизнеска ярдәм күрсәтү тора.

**Грузия**: Бизнес-омбудсмен яисә Салым омбудсмены, 2011 елда булдырылды.

Грузиядә Бизнес-омбудсмен вазыйфасы кертелү бу илдә фундаменталь салым реформасы һәм таможня режимының бер элементы гына булып тора. Грузиянең Салым кодексы омбудсменның бурычларын бик ачык тәгаенли: «...салым түләүчеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны күзәтергә, аларны үтәмәү очракларын ачыкларга, шулай ук бозылган хокукларны торгызуга ярдәм итәргә».

Кайбер илләрдә теге яисә бу хөкүмәт структуралары тарафыннан омбудсмен институты тиешле дәүләт органнары эшчәнлегенә бирелгән шикаятьләрне карап тикшерү өчен генә гамәлгә куелды:

**Бөекбритания**: Адъюдикатор Салым һәм таможня идарәсе, Дәүләт бәяләү идарәсе һәм Банкротлык буенча идарә эшчәнлегенә бирелгән шикаятьләрне карап тикшерә;

**Франция**: Икътисад һәм бюджет министрлыгы омбудсмены әлеге министрлык вәкаләтләренә керә торган очракларны карап тикшерә.[2]

Франциядә 2002 елда «Икътисад һәм бюджет министрлыгы омбудсмены» вазыйфасын булдыру өчен 1990 елның төп административ реформаның башлангычлары этәргеч бирде. Алар, аерым алганда, дәүләт идарәсенең гражданнар шикаятьләренә җавап бирү системасын яхшыртуга юнәлтелгән иде. 2004 елда, Икътисад һәм бюджет министрлыгы омбудсмены булдырылганнан соң ике ел узгач, рәсми булмаган «Дәүләт хезмәте омбудсменнары клубы» гамәлгә куелды. Бу клуб күп кенә дәүләт

[2] Франциядә дәүләт хезмәтенә караучы оешмаларда, почта хезмәтен, заводлар, телевидение һәм радио тапшырулары, тимер юллар, иминиятләштерү һ.б. оешмаларны да кертеп, 20 омбудсмен эшли.

предприятиеләренең (әйтик, Франция тимер юллары, кайбер милли телеканаллар, газ, су һәм электр белән тәэмин итү хезмәтләре, финанс институтлары) шушы чорда төзелгән омбудсменнарыннан тора. Икътисад һәм бюджет министрлыгы омбудсмены Министрлык эшчәнлегенә бәйле низагларны хәл итүдә арадашчылык вәкаләтләренә ия.

Евросоюзда Европа омбудсмены Европа Союзы институтлары эшчәнлегенә физик затлардан да, шулай ук Европада теркәлгән компанияләрдән дә шикаятьләр ала.

Башка күп кенә илләрдә, бизнес белән хөкүмәт арасындагы арадашчы буларак, институт еш кына төбәк дәрәҗәсендә эшчәнлек алып бара торган сәүдә-сәнәгать палаталары тарафыннан хезмәт күрсәтү органы булып тора.

Бу, әйтик, Испания һәм Австрия өчен хас.

Күп кенә илләрдә башка төрле «омбудсмен» институтлары эшли, аларга «бизнес компонентлары керә». Аларның кайберләре үтә тәгаен мандатка ия булганлыктан, аерым каралмады (әйтик, Коньяк Кореядагы Чит ил инвестицияләре аппараты чит ил инвестицияләре булган компанияләргә кагылышлы мәсьәләләр белән генә шөгыльләнә). Күпчелек очракта «бизнес-компонентлы омбудсменнар» үзләренең турыдан-туры функциясен үти: физик затларның (заказчылар, клиентлар, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар) хезмәт күрсәтүче предприятиеләргә карата шикаятьләре белән эшләп, эшкуарларны хөкүмәт оешмаларының законга каршы гамәлләреннән яклыйлар.

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫ КАРШЫНДАГЫ ЭШКУАРЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ

Россиядә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институтын булдыру – бизнес үзе – көн саен административ киртәләргә юлыгучы, түрәләрнең, хокук саклау органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең гадел булмаган гамәлләренә, еш кына басым ясавына дучар булучы, коррупция очракларыннан, гамәлдәге законнарның камил булмавыннан һәм башка шундыйлардан зыян күрүче эшкуарларның турыдан-туры үзләре тарафыннан көн тәртибенә куелган ихтыяҗ.

Россия Федерациясе Президентының «Озак вакытка исәпләнгән дәүләт икътисадый сәясәте» 2012 елның 7 маендагы 596 номерлы Указы нигезендә икътисадый сәясәтне камилләштерү чаралары билгеләнде, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенә федераль дәрәҗәдә һәм регионнар дәрәҗәсендә эшчәнлек алып баручы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институтын булдыру турында йөкләмә бирелде.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча беренче вәкаләтле вәкил – Борис Юрьевич Титов – Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 22 июнендәге 87 номерлы Указы белән билгеләп куелды.

2013 елның 7 маенда «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» ФЗ-78 номерлы Федераль Закон кабул ителде. Анда федераль дәрәҗәдә һәм төбәкләр дәрәҗәсендә вәкаләтле вәкилләр эшчәнлегенең хокукый нигезләре, статусы, аларны билгеләү тәртибе, хокукый гарантияләр һәм аларның вәкаләтләре билгеләнә.

2013 елның 02 ноябрендәге «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» ФЗ-294 номерлы Федераль закон белән күрсәтелгән Федераль законга Вәкаләтле вәкилнең компетенцияләрен киңәйтү һәм тәгаенләүгә юнәлтелгән үзгәрешләр кертелде.

Бүгенге көндә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең

институт буларак нигезе, ул нигезләнә торган законнар базасы булдырылган.

Эшкуарлык, юридик һәм экспертлык җәмгыятьләренең бизнес-омбудсмен каршындагы консультация советлары эшчәнлегендә генә катнашып калмыйча, мөрәҗәгатьләр белән эшләүгә дә җәлеп ителгән вәкилләре йөзендә граждан җәмгыятенә таяну – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институтының үзенә генә хас аерымлыгы булып тора. Бу мөрәҗәгатьләргә югары дәрәҗәдә экспертиза ясауны, шулай ук аларны карап тикшерүне җәмәгатьчелек тарафыннан контрольдә тотуны, шулай ук әлеге эшнең һәркемгә аңлаешлылыгын тәэмин итә.

Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

- эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлүен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

- эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән иҗтимагый институтларны үстерүгә ярдәм итү;

- эшкуарлар берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

- эшкуарлык эшчәнлеген үстерү һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу.


Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген оештыру ягыннан, хокукый, аналитик, мәгълүмати, документлар белән, финанс һәм матди-техник тәэмин итүне Иҗтимагый палата базасында оештырылган Вәкаләтле вәкил Аппараты башкара.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил хакимият органнарыннан бәйсез һәм турыдан-туры Россия Федерациясе Президентына буйсына. Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты тарафыннан эшкуарлар берлеге фикерен исәпкә алып билгеләп куела.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасы Россия Федерациясе Президенты Администрациясенә «кертелгән» Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасы булып тора.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан Вәкаләтле вәкил каршындагы Советлар (Иҗтимагый, Эксперт, Координация) гамәлгә куелды, аның төрле юнәлештә эшләүче  җәмәгатьчелек вәкилләре билгеләнде.

Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты структурасы.




Вәкаләтле вәкил каршындагы **Эксперт советы** Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген экспертизалар һәм консультацияләр бирү ягыннан тәэмин итү өчен төзелә. Совет юристлар һәм экспертлар җәмгыятьләренең абруйлы вәкилләре,  эшкуарларның эре берләшмәләре вәкилләреннән оештырыла.

Эксперт советының төп бурычлары түбәндәгеләр:

- законнарны һәм хокук куллану практикасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

- эшкуарларның хокукларын бозуга китерә торган системалы проблемаларны һәм коррупциячел практикаларны ачыклау һәм анализлау;

- халык алдында чыгышларда куллану өчен мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;

- эшкуарлар хокукларын саклау белән бәйле вазгыять турында докладлар әзерләү.

Вәкаләтле вәкил каршындагы **Иҗтимагый совет** эшкуарлар хокукларын яклау нәтиҗәлелеген арттыру максатларында хакимият һәм граждан җәмгыяте вәкилләре хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырыла.

Совет составына эшкуарлар берләшмәләре, эксперт, юридик һәм хокук саклау оешмалары вәкилләре, шулай ук Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы вәкиле, Вәкаләтле вәкил каршындагы Координация советы вәкиле һәм Вәкаләтле вәкил Аппараты Җитәкчесе керә.

Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрне тикшерүнең ачыктан-ачык алып барылуын, аңлаешлы булуын тәэмин итү;

- Вәкаләтле вәкил адресына кергән эшкуарлар мөрәҗәгатьләренә экспертиза ясауда граждан җәмгыяте катнашуын тәэмин итү;

- Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре билгеләнә торган юнәлешләр исемлеге буенча фикер алышу;

- Вәкаләтле вәкилнең юнәлешләр буенча вәкилләренә кандидатуралар турында фикер алышу;

- төбәкләрдә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр кандидатуралары буенча фикер алышу;

- эшкуарлар хокукларын яклау өлкәсендә бизнес һәм хакимиятнең үзара хезмәттәшлеге проблемаларын ачыклау һәм анализлау;

- эшкуарлар хокукларын яклау өлкәсендә законнарны һәм хокук куллану практикасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

- Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын үтәү турында Россия Федерациясе Президентына еллык доклад турында фикер алышу;

- эшкуарлар хокукларын яклау функцияләрен гамәлгә ашыручы җәмәгать оешмаларының Вәкаләтле вәкил, федерация субъектлары вәкаләтле вәкилләре адресына кергән мөрәҗәгатьләргә экспертиза ясауда катнашуы мөмкинлекләре һәм рәвешләре турында фикер алышу;

- Вәкаләтле вәкилнең федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының норматив булмаган актлары гамәлен вакытлыча туктату күрсәтмәләре чыгару турындагы карарлары буенча фикер алышу;

- Вәкаләтле вәкилнең вазыйфаи затлар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге алып баруга комачаулык иткән вазыйфаи затларны, әгәр дә аларның әлеге гамәлләрендә җинаять буларак җәза бирелергә тиешле эшчәнлек билгеләре булмаса, вакытлыча эшеннән азат итү яисә дисквалификацияләү турында күрсәтмәләр чыгару хакындагы карарлары буенча фикер алышу.

Вәкаләтле вәкил каршындагы **Координация советы** Вәкаләтле вәкилнең юнәлешләр буенча вәкилләре (җәмәгатьчелек омбудсменнары) эшчәнлеген координацияләү өчен оештырыла. Аның составына җәмәгатьчелек омбудсменнары һәм Эксперт советы Рәисе керә.

Вәкаләтле вәкил каршындагы Координация советы түбәндәге бурычларны башкара:

- Вәкаләтле вәкил Аппараты белән бергәләп эшкуарларның шикаятьләрен һәм мөрәҗәгатьләрен системалаштыра һәм гомумиләштерә, эшкуарлар өчен аеруча проблемалы тармакларны һәм ведомстволарны аерып билгели;
- эшкуарлык эшчәнлегенең берничә юнәлешенә (өлкәсенә) кагылышлы мәсьәләләр, эшкуарлар мөрәҗәгатьләре буенча эшне координацияли;
- ачыкланган проблемаларны бетерү һәм тәкъдим ителгән карарларны уздыру өчен җәмәгатьчелек белән элемтәләр һәм хакимият органнары белән элемтәләр буенча мәгълүмати сәясәтне билгели;
- Эшкуарлыкның Җәмәгатьчелек омбудсмены билгеләүне таләп итә торган аеруча проблемалы өлкәләрен билгели;
- абруйлы һәм тиешле өлкәдә танылган экспертлар арасыннан Җәмәгатьчелек омбудсменнарына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертә;
- эшкуарлар хокукларын яклау эшчәнлеге белән бәйле мәгариф программалары һәм уку-укыту юнәлешләре буенча тәкъдимнәр бирә;
- Җәмәгатьчелек омбудсменнары эшчәнлегендә мәнфәгатьләр каршылыклары килеп чыгу очракларын карап тикшерә, аларны бетерү чаралары тәкъдим итә.

**«Бизнес коррупциягә каршы» иҗтимагый процедуралар үзәге (алга таба – Үзәк)** - бизнес һәм рейдерлыкка, коррупциячел басымга каршы көрәшү өчен оештырылган Россиянең эшлекле җәмәгатьчелеге, дәүләт структуралары, җәмәгать оешмалары вәкилләрен берләштергән коммерциячел булмаган оешма.

Үзәк эшкуарларның Вәкаләтле вәкилгә җинаять эшләре һәм коррупция белән бәйле мөрәҗәгатьләренә иҗтимагый экспертиза уздыру белән шөгыльләнә һәм алынган мөрәҗәгатьләрне экспертизалауга «pro bono» принциплары нигезендә юристларны җәлеп итә. Юридик ассоциацияләр әгъзалары Вәкаләтле вәкил институтына хокукый ярдәмне Үзәк белән үзара хезмәттәшлек нигезендә күрсәтәләр.

Үзәк түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- эшкуарларның Үзәккә яисә Вәкаләтле вәкилгә җибәрелгән, җинаять эзәрлекләве, рейдерлык һәм коррупция белән бәйле эшләр буенча мөрәҗәгатьләрен тикшерү (Вәкаләтле вәкил йөкләве буенча);

- әлеге эшләр буенча низагта катнашучы якларны җәлеп итеп халык алдында фикер алышулар уздыру;

- мөрәҗәгатьне карап тикшерү йомгаклары буенча җәмәгатьчелек карары чыгару.

Үзәкнең идарә органнары түбәндәгеләр – Үзәк Президиумы һәм Башкарма директоры. Идарә органнарыннан тыш, Үзәктә Иҗтимагый һәм Күзәтчелек советлары эшли.

Үзәкнең Иҗтимагый советына эшкуарлар, сәясәтчеләр, һөнәри нигездә эшләүче юристлар һәм икътисадчылар, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре арасыннан экспертлар керә.

Үзәкнең Күзәтчелек советы составына дәүләт хакимияте федераль органнарының коррупциягә каршылык күрсәтү буенча эштә турыдан-туры катнашучы һәм үз компетенцияләре чикләрендә коррупция һәм рейдерлык мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрне карап тикшерергә вәкаләтле вәкилләре керә.

**Вәкаләтле вәкилгә түләүсез хокукый экспертлык ярдәме («pro bono»)** җайга салуның аерым тармакларында компетентлы һөнәри нигездә эшләүче юристлар (алга таба – Юрист-экспертлар) тарафыннан күрсәтелә ала.

Хокукый экспертлык ярдәме Вәкаләтле вәкил каравына кергән эшкуарлар мөрәҗәгатьләренә хокукый бәяләмә бирү, эшкуарлар хокукларын яклау өчен юридик күрсәтмәләр эшләү максатларында гамәлгә ашырыла.

**Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре** (алга таба - җәмәгатьчелек омбудсменнары) җәмәгать башлангычында эшлиләр һәм Вәкаләтле вәкилнең аның адресына килгән эшкуарлык эшчәнлеген җайга салуның төрле өлкәләренә караган эшкуарлар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча ярдәмчеләре булып торалар.

Җәмәгатьчелек омбудсменнары Вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле өлкәдә абруйлы һәм танылган экспертлар арасыннан билгеләнә, алар экспертлык һәм вәкиллек функцияләрен башкаралар.

**Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләре**

Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе территориясендә Вәкаләтле вәкил компетенциясенә караучы мәсьәләләр буенча, аерым алганда, Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләр әзерләгәндә, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына консультатив һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтүче җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләре булдырырга хокуклы.

Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләре түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә:

- эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләр буенча консультацияләр оештыру;
- эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләре материаллары буенча беренчел экспертиза оештыру;
- эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларын яклау мәсьәләләре кысаларында кыска вакытка исәпләнгән уку программалары оештыру;
- эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокуклары бозылуның типик очраклары һәм аларны хәл итү ысуллары турында мәгълүмат тарату;
- алга таба эшкуарлар хокукларын яклау буенча төбәктәге вәкаләтле вәкилгә җибәрү өчен материаллар (низагның кыскача тасвирламасы, эксперт бәяләмәсе һ.б.) әзерләү.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил һәм аның эш аппараты 2015 елның 1 гыйнварыннан юридик зат хокукы бирелгән дәүләт органы булачак.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ КАРШЫНДАГЫ ЭШКУАРЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Вәкаләтле вәкил) Россия Федерациясендә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институтының үзенә хас үзенчәлекләре, бурычлары һәм вәкаләтләре булган төбәк элементы булып тора.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең хокукый нигезләре Россия Федерациясе Конституциясеннән, «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2013 елның 7 маендагы 78-ФЗ номерлы Федераль законнан, Татарстан Республикасы Конституциясеннән, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законыннан, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

Татарстан Республикасында Вәкаләтле вәкил вазыйфасы 2013 елның гыйнварында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 24 гыйнварындагы ПУ-44 номерлы Указы нигезендә кертелде.

2013 елның 25 гыйнварында Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә Вәкаләтле вәкил билгеләп куелды.

«Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2013 елның 7 маендагы 78-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителгәннән соң, 2013 елның 5 июлендә Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Әлеге Закон кабул ителгәнчегә кадәр, Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Президенты указлары нигезендә алып барды.

Вәкаләтле вәкилнең бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларга юридик ярдәм күрсәтү;

2) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән иҗтимагый институтларны үстерүгә ярдәм итү;

3) эшкуарлык берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлүен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

5) эшкуарлык эшчәнлеген үстерү, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

6) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча мәгълүматны туплау, аны өйрәнү һәм анализлау;

7) эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлү һәм яклану торышы турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

Вәкаләтле вәкил алдында торган бурычларны үтәү бары тик тулы һәм нәтиҗәле эшчәнлек алып барыр өчен вәкаләтләр булганда гына мөмкин. Һәм биредә шуны да билгеләп үтәргә кирәк, гамәлдәге законнар Вәкаләтле вәкилгә ачыкланган хокук бозулар очракларын күрсәтү генә түгел, ә әлеге очракларны бетерү һәм гаепле затларны җавапка тартуда катнашу хокукы бирүче шактый киң вәкаләтләр бирә.

2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затлардан кирәкле белешмәләр, документлар һәм материаллар соратып алырга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, федераль закон белән аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән бүтән органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның норматив булмаган хокукый актларын гамәлдә түгел дип тану, аларның карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип тану турында гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә, әгәр дәгъвалана торган норматив булмаган хокукый акт, карар һәм гамәл (гамәл кылмау) законга

яисә башка норматив хокукый актка туры килмәсә һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозса, аларга нинди дә булса бурычларны законсыз йөкләсә, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка киртәләр тудырса;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге өлкәсенә карый торган норматив хокукый актлар кабул итү турында (норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү яисә аларның үз көчләрен югалтуын тану турында) дәлилле тәкъдимнәр җибәрергә;

4) Татарстан Республикасының эшкуарлык эшчәнлегенә кагылышлы законнары һәм башка норматив актлары проектларын әзерләүдә катнашырга, күрсәтелгән проектларны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр әзерләргә;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары актларын юкка чыгару яисә гамәлдә булуын туктатып тору турында Татарстан Республикасы Президентына дәлилле тәкъдимнәр җибәрергә;

6) гариза бирүченең язмача ризалыгы белән гариза бирүчегә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль кысаларында үткәрелә торган күчмә тикшерүдә катнашырга;

7) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына тоткарлыксыз кереп йөрергә;

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз компетенциясе кысаларында башка гамәлләр башкарырга.

Шул ук вакытта, башка гамәлләр дигәндә, махсус законнарда каралган гамәлләрне дә күздә тотарга кирәк, мәсәлән, шундыйлардан:

1) хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органнан күчемсез мөлкәткә хокукларны теркәү һәм аның белән килешүләр төзү турында түләүсез белешмәләр таләп итү хокукы;

2) монополиягә каршы органнан планнан тыш тикшерүләр үткәрүне таләп итү хокукы;

3) контрольдә тоту максатларында, махсус рөхсәт кәгазеннән башка җәзаларны үтәтү учреждениеләрендә һәм тикшерү изоляторларында булу;

4) махсус рөхсәт кәгазеннән башка, әлеге Федераль законда күрсәтелгән очракларда шик астына алынучыларны һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту өчен файдаланылучы җинаять-җәзаларны үтәтү системасының тикшерү изоляторларында, эчке эшләр органнарының һәм федераль куркынычсызлык хезмәте чик сагы органнарының шик астына

алынучылар һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторларында, шулай ук гауптвахталарда булу хокукы;

5) җәзаларны үтәтү учреждениеләрендә һәм органнарында, моның өчен махсус рөхсәттән башка булу хокукы.

Вәкаләтле вәкилнең хокукларын билгеләп үткәннән соң, әлеге институтка, чыннан да, алда торган мәсьәләләрне нәтиҗәле чишү өчен барлык мөмкинлекләр булуы аңлашыла. Шуңа бәйләп, Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген ресурс ягыннан тәэмин итүнең дә мөһимлеген билгеләп үтәргә кирәк. Татарстан Республикасында Вәкаләтле вәкил дәүләт хезмәте вазыйфасын биләп, турыдан-туры Татарстан Республикасы Президенты «канаты астында» эшли – шундый үзенчәлеккә ия.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген оештыру, хокукый, аналитика, мәгълүмати, документлар белән, финанс һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына йөкләнгән, шул максатларда 2013 елның көз аенда Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасында яңа структур бүлекчә – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге оештырылды.

Бүгенге көндә Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген җайга салу өчен кирәкле булган норматив база бар һәм штат саны 4 кешедән торган бүлек формалаштырылды.

Вәкаләтле вәкил эшен оештыру бары тик эчке ресурсларга нигезләнеп кенә алып барылмый, ул шулай ук тышкы мохит – иҗтимагый институтлар белән актив хезмәттәшлек алып баруга юнәлдерелгән.

**Эшкуарлык җәмгыятьләре белән үзара хезмәттәшлек**

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә эшләп килүче күп кенә эшкуарлык берләшмәләре белән тыгыз элемтәдә тормышка ашыра. Ике арада урнаштырылган элемтә ярдәмендә эшкуарлар үз эшчәнлекләрен тормышка ашырганда килеп туган каршылыклар турында кыска вакыт эчендә мәгълүмат алырга мөмкинлек туа. Вәкаләтле вәкил даими рәвештә эшкуарлык эшчәнлеге алып баруга һәм үстерүгә киртә булырдай каршылыклар тематикасына багышланган эшкуарлар җәмгыятьләре утырышларында катнашып килә. Мондый чараларга Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, ТР кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе, Татарстан Республикасының фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары

ассоциацияләре, Татарстан Республикасының текстиль һәм җиңел сәнәгать эшкуарлары берлеге, Татарстан Республикасы базарлары берлеге һ.б. утырышлары керә.

**Pro bono экспертлары**

Вәкаләтле вәкил, бергәләп эшләү өчен, Татарстан Республикасы территориясендәге аеруча эре юридик агентлыкларны җәлеп итте. 2013 елда салым өлкәсендә җайга салу, монополиягә каршы законнар, дәүләт сатып алулары, лицензияләр бирү, интеллектуаль милек, дәүләт-шәхси партнерлыгы, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, тариф һәм таможня өлкәсендә җайга салу мәсьәләләре буенча махсуслашкан юридик компанияләр белән хезмәттәшлек турында 12 килешүгә кул куелды.

Юридик компанияләр белән хезмәттәшлек кысаларында эшкуарлар мөрәҗәгатьләрен бергәләп карап, һәр мөрәҗәгатькә юридик бәяләмә әзерләнә. Моннан тыш, эшкуарлык мохитенә чиктән тыш басым ясауны ачыклауга, эшкуарлык юлында административ киртәләрне киметүгә юнәлтелгән системалы мәсьәләләр өйрәнелә, шулар нигезендә гамәлдә булган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү һәм (яисә) аларны үз көчләрен югалткан дип тану турында тиешле тәкъдимнәр әзерләнә.

**Югары уку йортлары белән үзара эшчәнлек**

Казан (Идел буе) федераль университеты белән бергәләп хәзерге вакытта эксперт-аналитика советы төзү буенча эш алып барыла. Советның төп бурычы – билгеле очракта эшкуарлар хокукларын бозуның булуы яисә булмавы турында бәяләмә белән Вәкаләтле вәкилгә килгән эшкуарлар мөрәҗәгатьләренә эксперт бәясе бирү, шулай ук эшкуарлар хокукларын бозу очракларын гомумиләштерү һәм анализлау. Бәйсез экспертлар, күп очракта хокукый җайга салуның теге яисә бу өлкәсендә танылган белгечләр тарафыннан бирелгән мондый бәяләмәләр эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын кире кайтару өчен саллы дәлил булырга мөмкин. Моннан тыш, Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары җитәкчеләре һәм юристлары өчен университетның профессор-укытучылар составын җәлеп итеп, түләүсез уку семинарлары уздыру планлаштырылды.

**Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләре**

2013 елда Вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе арасында хезмәттәшлек һәм үзара эшчәнлек турында килешүгә кул куелды.

Хезмәттәшлекнең төп юнәлеше булып Эшкуарлыкка булышлык күрсәтү үзәге нигезендә Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Чистай, Арча, Буа шәһәрләрендә, Актаныш авылында җәмәгать кабул итү бүлмәләре оештыру тора.

Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләрендә эшкуарлардан килгән шикаятьләр карала, аларга беренчел экспертиза уздырыла, шулай ук Вәкаләтле вәкил компетенциясенә турыдан-туры карамаучы, әмма эшкуарлык эшчәнлеге алып бару тәртибе белән бәйле мәсьәләләр буенча язмача һәм телдән консультацияләр бирелә.

Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләре оештыру Вәкаләтле вәкилнең эшкуарлык берләшмәләре белән хезмәттәшлек чикләрен шактый киңәйтергә мөмкинлек бирде. Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләрен ачканнан соң, 2013 елның беренче кыш айларында Вәкаләтле вәкил аппаратына 10 нан артык язма һәм телдән мөрәҗәгать килде.

**Дәүләт хакимияте органнары белән үзара эшчәнлек**

Вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте органнары һәм республиканың җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары белән үзара эшчәнлек алып бара.

Дәүләт хакимияте башкарма органнары, хокук саклау органнары белән үзара нәтиҗәле эшчәнлек алып бару максатларында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Идел буе районара табигатьне саклау прокуратурасы, Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе, Россия монополиягә каршы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән килешүләр төзелде.

Вәкаләтле вәкил  алда күрсәтеп үтелгән дәүләт һәм хокук саклау органнары белән үзара эшчәнлек кысаларында эшкуарлыкны үстерү һәм яклау өлкәсендә мәсьәләләрне чишү өчен төзелгән эксперт, киңәшмә һәм консультацияләр бирү советлары составында эшли.


Шулар арасында – Татарстан Республикасы Прокуратурасы каршындагы эшкуарларны яклау буенча ведомствоара эш төркеме, Чаллы шәһәре Прокуратурасы каршындагы эшкуарларны яклау буенча ведомствоара эш төркеме, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

каршындагы Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка булышлык күрсәтү һәм үстерү мәсьәләләр буенча координация советы, Татарстан Республикасының Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы каршындагы эш төркеме, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе каршындагы эш төркеме, Татарстан Республикасы Инвестиция советы һәм башкалар.

2013 елда Россия Федерациясе Президентының Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары, Идел буе федераль округында инвестицияләр буенча вәкаләтле вәкиле  Г.С. Изотова рәислегендә Эшкуарлар хокукларын саклау буенча вәкаләтле вәкил советы төзелде.


Идел буе федераль округы чикләрендә булган Россия Федерациясе субъектларындагы Эшкуарлар хокукларын саклау буенча вәкаләтле вәкил советы коллегиаль киңәшмә органы булып тора, ул кече һәм урта эшкуарлыкны үсеше өчен шартларны камилләштерү, административ киртәләрне киметү, Идел буе федераль округындагы эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү буенча Идел буе федераль округында булган Россия Федерациясе субъектларында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр эшчәнлеген координацияләү һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру эшен алып бара.

## ЭШКУАРЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ СУБЪЕКТЛАРЫ МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРЕН АНАЛИЗЛАУ




2013 елның 11 аенда (февральдән декабрьгә кадәр) Вәкаләтле вәкилгә 201 мөрәҗәгать керде. Шуларның 76 сы – телдән мөрәҗәгать, 125 е – язмача.

Телдән мөрәҗәгатьләр нигездә финанс, бизнесны үстерү һәм продукцияне сату мәсьәләләренә кагыла. Телдән мөрәҗәгатьләр буенча очрашулар уздырылды, шулай ук мөрәҗәгатьтә ассызыклап үтелгән сорауларны чишү ысуллары турында тәкъдимнәр һәм аңлатмалар бирелде.





125 язмача мөрәҗәгатьнең 82 се каралды. Шул ук вакытта әлеге мөрәҗәгатьләрнең 25 ендә хокук бозу очраклары булуы расланды.

Вәкаләтле вәкил тикшергәннән соң, эшкуарлар хокуклары торгызылды. 57 язмача мөрәҗәгать буенча мөрәҗәгать итүчеләргә, хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган очракта, аларны саклап калуның тиешле ысулларын файдалану турында аңлатмалар һәм тәкъдимнәр бирелде.

2013 елның ахырында кергән 43 мөрәҗәгать буенча агымдагы 2014 елда эш алып барыла.

Әгәр дә мөрәҗәгатьләрнең төрләре турында сөйләсәк, аларны җинаять эшләре белән бәйле мөрәҗәгатьләргә – андыйлар 2013 елда барлыгы 15 булды, һәм административ хокук бозулар белән бәйле – андыйлар 2013 елда иң күбе, барлыгы 110 мөрәҗәгать – бүләргә мөмкин. Җинаять эшләре белән бәйле мөрәҗәгатьләр арасында эшкуарларны нигезсез җавапка тарту очракларына шикаятьләр (12 мөрәҗәгать), шулай ук шикаять белдерүче фикеренчә, «рейдер басып алулары» кебек күренешләр булганда да, җинаять эшләрен караудан нигезсез рәвештә баш тарту очракларына (3 мөрәҗәгать) шикаятьләр белдерү бар иде. Барлыгы җинаять эшләре белән бәйле мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкил исеменә килгән язмача мөрәҗәгатьләрнең 9,8% ын тәшкил итә.

Әгәр дә административ характердагы мөрәҗәгатьләргә анализ ясарга теләсәк, аны кергән барлык мөрәҗәгатьләрне гомумиләштергәннән соң билгеләнгән хокук бозу өлкәләренә нигезләнеп ясау максатка ярашлы булыр иде. Әлбәттә, болай бүлү шартлы төстә генә, чөнки еш кына бер мөрәҗәгатьтә берничә өлкәдә булган хокук бозулар турында әйтелә. Чөнки, кагыйдә буларак, бизнесны киңәйтүгә каршы киртәләр турында сүз алып барганда, эшкуарлар нигезсез рәвештә җир участогы бүлеп бирүдән баш тартучы муниципаль берәмлек вазыйфаи затларының законсыз гамәлләре турында әйтәләр, тикшерү барышында соралучы җир участогы башка затка аның гавами тәкъдиме буенча законнарда билгеләнгән процедураларны үтәмичә бирелгән икәнлеге ачыклана, ә бу конкуренцияне




киметүгә китерә. Бу очракта мөрәҗәгатьне җир һәм мөлкәт өлкәсенә дә, шулай ук монополиягә каршы эшчәнлекне җайга салу өлкәсенә дә бирергә була.

**Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә хокук бозулар**

Димәк ки, язмача мөрәҗәгатьләрне анализлау нәтиҗәләре шуны күрсәтә, эшкуарлар өчен аеруча четерекле өлкә булып «җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре» өлкәсе тора, мөрәҗәгатьләрдә язылган барлык

мәсьәләләрнең дүрттән бер өлешеннән аз гына артыграк урынны, ягъни 25,5 % өлешне били. Эшкуарларның җир һәм мөлкәт өлкәсендә килеп туган төп каршылыклар түбәндәгеләр:

- җирле үзидарә органнарының хаксыз рәвештә җир участогын бирүдән баш тартулары;
- җир участокларын алуга гаризаларны карау вакытын сакламау;
- хаксыз рәвештә мөлкәтне тартып алу;
- суд актларын тормышка ашыру процедурасын сузу, бу очракта кассацион шикаять бирүне сылтау итеп, законлы көченә кергән һәм апелляция инстанциясенең суд карары вәкаләтле орган тарафыннан үтәлми.

**Тикшерүләр уздырганда хокук бозулар**

Кабул ителгән мөрәҗәгатьләр арасында сан ягыннан икенче урында «тикшерүләр уздыру» өлкәсе тора. Бу тематика буенча мөрәҗәгатьләр барлык мөрәҗәгатьләрнең 13 % ын тәшкил итә. Әлеге өлкәдә эшкуарлар күрсәткән хокук бозулар арасында түбәндәгеләрне ассызыклап үтәргә мөмкин:

- тикшерү уздыру процедурасын үтәмәү;
- тикшерү уздыру вакытын сакламау;
- планнан тыш тикшерүләр уздырганда прокуратура белән килешү булмавы.
-

**Авыл хуҗалыгы**

Әлеге өлкәдәге мөрәҗәгатьләрнең 10,5 % ы түбәндәгеләр белән бәйле:

- хуҗалык итүнең кече формаларына субсидияләр бирү вакытын сакламау;
- җир участогын җир кишәрлеге исәбеннән бүлеп бирү процедураларының кыенлыгы һәм авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җирләрнең җитмәве.

**Башка өлкәләр**

«Салымнар» өлкәсендә мөрәҗәгатьләр – 5,8 %ны, «Финанс ярдәме күрсәтү» өлкәсендә – 5,2 %ны, «Аренда мөнәсәбәтләре» өлкәсендә – 3,9 %ны, «Башкарма производство» өлкәсендә – 3,2 %ны, «Монополиягә каршы җайга салу» өлкәсендә – 3,3 %ны, «Административ җаваплылыкка тарту»

өлкәсендә – 3,5 %ны, «Техник җайга салу» өлкәсендә – 2,6 %ны, «Пенсия кертемнәре» 2,6 %ны тәшкил итә.

«Башка мәсьәләләр» бүлегенә бөлгенлек өлкәсенә, кредит шартнамәләре буенча йөкләмәләрне үтәү, суд производствосы, хезмәт күрсәтү, шулай ук таможня өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр керә.

**Мөрәҗәгатьләр керү ысулларын анализлау**

Татарстан Республикасы эшкуарларыннан Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләр турыдан-туры да, шулай ук башка дәүләт хакимияте органнары, җәмгыять берләшмәләре һәм башка оешмалар аша җибәрелде.

Шулай итеп, Вәкаләтле вәкилгә карау өчен кергән 125 язмача мөрәҗәгатьнең 15 е – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Аппаратыннан, 14 е – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, 15 е – җәмәгать берләшмәләреннән, 3 мөрәҗәгать «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җәмәгать кабул итү бүлмәләре аша җибәрелде. Калган 78 мөрәҗәгать Вәкаләтле вәкилгә турыдан-туры килде.

Татарстан Республикасында Вәкаләтле вәкил вазыйфасы 2013 елның гыйнвар аенда гына кертелүгә дә карамастан, мөрәҗәгатьләрнең күбесе Вәкаләтле вәкил адресына турыдан-туры килде, бу исә эшкуарларның үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда тагын бер ышаныч артуы турында хәбәрдар булуын күрсәтә.





**Низаг стадиясе**

Эшкуарның Вәкаләтле вәкилгә низагның кайсы стадиясендә мөрәҗәгать итәргә карар бирүен ачыклау шулай ук бик мөһим. Гамәлдәге законнарда эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, шулай ук аларның вазыйфаи затларының законга каршы гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка шикаять бирү хокукы бар. Вәкаләтле вәкил низагны хәл итү өчен аның теләсә кайсы стадиясендә катнашырга хокуклы.

Шулай итеп, 2013 елда мөрәҗәгать иткән барлык эшкуарларның 79 % ы, ягъни барлыгы 99 эшкуар судка биргәнчегә кадәр шикаятьләрен Вәкаләтле вәкилгә җибәрде. Шулар арасында 21 эшкуарның хокуклары торгызылды (бу – уңай нәтиҗә белән каралган мөрәҗәгатьләрнең 84% ы), 50 мөрәҗәгать буенча хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу өчен эшләргә кирәкле гамәлләр турында консультацияләр бирелде. Әлеге төргә караган калган 28 мөрәҗәгать буенча эш 2014 елда дәвам иттерелде.

Эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары 8 % очракта (10 мөрәҗәгать) Вәкаләтле вәкилгә суд тикшерүе барышында мөрәҗәгать итте. 3 мөрәҗәгать буенча хокуклар торгызылды, 2 мөрәҗәгать буенча хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу өчен эшләргә кирәк булган гамәлләр тәртибе турында консультацияләр бирелде, 5 мөрәҗәгать буенча эш дәвам итә.

16 очракта эшкуарлар Вәкаләтле вәкилгә инде суд тикшерүләре тәмамлангач мөрәҗәгать итте. Бу очракта бары тик бер мөрәҗәгать буенча гына уңай нәтиҗәгә ирешергә мөмкин булды, эшкуар дәүләт органының аның файдасына кабул ителгән суд карарын үтәмәвенә шикаять белдерде. 4 мөрәҗәгать буенча хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу өчен эшләргә кирәкле гамәлләр турында консультацияләр бирелде. Калган мөрәҗәгатьләр буенча эш дәвам итә.




Вәкаләтле вәкилгә низагның төрле стадияләрендә мөрәҗәгать иткән эшкуарларның хокукларын торгызу буенча эшкә анализ ясау шуны күрсәтә, эшкуар файдасына булмаган суд карары үз көченә кергәннән соң, Вәкаләтле вәкилнең низагны хәл итүгә булышу чаралары кими. Еш кына шундый хәл килеп чыга, эшкуарлар башта ук хокукларын яклауның нәтиҗәле булмаган ысулын сайлау сәбәпле, әлеге стадиядә аны хәл итү шактый кыен була. Шуңа күрә, сүз дә юк, мөрәҗәгатьләрне уңай хәл итү каршылыкның үсеп, үзенең иң соңгы чигенә җитүен көтеп тормыйча, эшкуар Вәкаләтле вәкилгә дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, шулай ук аларның вазыйфаи затларының законга каршы гамәлләре (гамәл кылмаулары) фактлары килеп тугач ук, кичектермичә мөрәҗәгать иткәндә генә мөмкин булачак.

**Мөрәҗәгатьләрнең колачы**

Үзләренең язмача мөрәҗәгатьләрендә эшкуарлар республиканың 25 муниципаль районы һәм 2 шәһәр округы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль органнар, шулай ук хуҗалык субъектларына шикаять белдерде. Биш очракта эшкуарлар Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына шикаять язды. Бередә нәкъ менә хокук бозу өлкәләренә кагылышлы шикаятьләрдәге кебек үк, бер эшкуарның мөрәҗәгатендә дәүләт хакимияте органнары,

шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан хокук бозулар турында да мәгълүмат булырга мөмкин. Шулай итеп, ташламага ия гражданнарны йөрткән өчен компенсациянең түләнмәве турында мөрәҗәгатьтә башкарма хакимият органының гамәл кылмавы турында әйтелә, ә менә мөрәҗәгатьне карау барышында җирле үзидарә органнарының тиешле дәүләт органына әлеге компенсацияне исәпләп чыгару өчен кирәкле булган барлык документларны да җибәрмәве ачыклана. Шул вакытта Вәкаләтле вәкил муниципаль орган белән дә, дәүләт хакимияте органы белән дә эш алып барды.

Әлеге бүлекне караганда, шуны да истә тотарга кирәк, әгәр дә эшчәнлегенә шикаять бирелгән дәүләт хакимияте, җирле үзидарә, хуҗалык итүче субъект органы (шул исәптән Министрлыклар, суд органнары) Казан шәһәрендә урнашкан булса, хокук бозу Казан шәһәрендә булган дип санала.

| Муниципаль берәмлекнең атамасы | Муниципалитетлар ничә тапкыр искә алынган |
|---|---|
| Әгерҗе | 1 |
| Актаныш | 2 |
| Әлки | 1 |
| Әлмәт | 4 |
| Апас | 2 |
| Арча | 1 |
| Бөгелмә | 5 |
| Югары Ослан | 1 |
| Биектау | 2 |
| Чүпрәле | 1 |
| Алабуга | 4 |
| Зәй | 3 |
| Зеленодольск | 5 |
| Казан | 47 |
| Кайбыч | 1 |
| Кама Тамагы | 7 |
| Лаеш | 1 |
| Лениногорск | 2 |
| Мамадыш | 1 |
| Минзәлә | 2 |
| Мөслим | 1 |
| Чаллы | 16 |
| Нурлат | 2 |
| Питрәч | 2 |

| | |
|---|---|
| Спас | 2 |
| Тәтеш | 1 |
| Тукай | 1 |
| Чистай | 2 |
| Ютазы | 5 |
| *ТР нан читтә урнашкан шәһәрләр (Мәскәү, Калининград, Ульяновск)* | *5* |


Башкарма комитетлар һәм муниципаль берәмлекләр башлыкларына карата шикаять белдерелгән муниципаль берәмлекләр арасында Казан шәһәре беренчелекне тота.

Шулай итеп, 2013 елда җирле үзидарә органнарына карата шикаять белдергән 47 мөрәҗәгатьнең 15 е Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, төгәлрәк итеп әйткәндә, Җир һәм Мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетына, Капиталь төзелеш идарәсенә, Казан шәһәре районнары администрацияләренә карата иде.



Тәҗрибә шуны күрсәтә, эшкуарлар еш кына теге яки бу яктан аның хокукларын бозган эшкуарлык эшчәнлегенең башка субъектына карата шикаять белдерә. Мондый мөрәҗәгатьләр, шикаять белдерүче фикеренчә, килеп туган хокук бозуларны тиешле дәрәҗәдә бетермәгән теге яки бу дәүләт хакимияте яисә җирле үзидарә органына карата шикаятьне дә үз эченә алырга мөмкин.


Шулай итеп, 2013 елда 125 язмача мөрәҗәгатьтә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм/яисә хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан эшкуарлар хокукларының бозылуы турында 165 тапкыр искә алына. Шул мөрәҗәгатьләрнең 28ендә эшкуарлык эшчәнлегенең башка субъектларына шикаятьләр, ә калган 137 очракта – дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына шикаятьләр белдерелде.




**Эшчәнлекләренә карата аеруча күп шикаять белдерелгән органнар**

Әгәр дә дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына карата белдерелгән шикаятьләр структурасын җентекләп өйрәнсәк, шикаятьләрнең нигездә башкарма комитетлар һәм муниципаль берәмлекләр башлыклары эшчәнлегенә карата килүе турында нәтиҗә ясарга булыр иде.

Эшчәнлекләренә карата шикаять бирелү буенча икенче урында хокук саклау органнары тора, мондый мөрәҗәгатьләр – 19. Өченче урында – Татарстан Республикасы министрлыклары. Аларның эшенә шикаять белдерелгән 13 мөрәҗәгать килде.




Хокук саклау органнарына кагылышлы 20 шикаятьнең 8 е – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе, 12 шикаять – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча структур бүлекчәләре гамәлләренә карата.

8 очракта эшкуарлар Россиянең башка субъектларындагы дәүләт хакимияте органнары хезмәткәренә карата шикаять белдерде.

Республиканың башкарма хакимияте органнарына кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең 3 сендә крестьян-фермер хуҗалыгы башлыкларына ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, 2 мөрәҗәгатьтә урман кишәрлеген бирүдән нигезсез рәвештә баш тарту мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм ташламага ия гражданнарны йөртүгә компенсация түләүне тоткарлау мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы эшчәнлегенә карата шикаять белдерелгән иде.

Барлык мөрәҗәгатьләргә анализ ясаганнан соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин:

1) мөрәҗәгатьләрнең шактый өлеше административ киртәләр белән бәйле, шул исәптән җинаять җаваплылыгына тарту турында мөрәҗәгатьләр эшкуарлык эшчәнлеге алып баруда кыенлыклар гына тудырып калмый, ә бизнесның тулысынча бетүенә китерү очракларын да күрсәтә;

2) җирле үзидарә органнарының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә хокук бозулар аеруча күп, шул исәптән мондый шикаятьләрнең күпчелеге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты адресына килә;

3) эшкуарның дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары белән каршылыгы яңа гына барлыкка килү стадиясендә эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау нәтиҗәлерәк була. Мондый очракларда эшкуарның хокукларын кире торгызу мөмкинлеге күпкә арта;

4) эшкуарлар еш кына җирле үзидарә органнарының һәм аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерә. Гаҗәп тә түгел, эшкуарлар билгеле бер территориядә эшли һәм эшкуарлык эшчәнлеге алып бару өчен ресурсларны бүлү мәсьәләләре нәкъ менә аның чикләрендә хәл ителә.

## ИРЕШЕЛГӘН УҢЫШЛАР

Вәкаләтле вәкил 2013 елда эшчәнлеген башлап кына җибәрде; аның эшчәнлеген регламентлаштыручы актлар бары кабул ителгән генә иде әле; Россия өчен дә, Татарстан өчендә яңа әлеге институтны булдыруның башлангыч чорында бирелгән вәкаләтләр һәм компетенцияләрнең ниндирәк нәтиҗәләр бирәсен бик азлар гына тулысынча бәяли ала иде, ә иң мөһиме – эшкуарларның әлеге институтка мөнәсәбәте ниндирәк буласын, үз проблемалары белән, яклау сорап, Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итү-итмәвен әйтүе кыен иде.

Әмма инде хәзер үк эшкуарларның бу эшкә битараф калмады, Вәкаләтле вәкил исеменә беренче эшчәнлек елы өчен шактый күп мөрәҗәгать керде дип әйтергә нигез бар. Әйе, телдән мөрәҗәгатьләр күп булды: вәкаләтле органнар белән хезмәттәшлек иткәндә юридик консультация кирәк булгач, теге яисә бу гамәлләр башкару тәртибен ачыклар өчен эшкуарлар телефоннан шалтыратып та мөрәҗәгать иттеләр, кайчак алар телдән гомуми характердагы проблемалар: салымнарның зурлыгы, бюрократларның киртәләр коруы, еш кына үзгәреп торучы законнар турында хәбәр иттеләр. Әмма билгеле бер очракларда, теләсә кайсы мөрәҗәгать җентекле һәм тирәнтен тикшерүне, документларны, вәкаләтле органнар белән үзара язышу алып баруны, судлар чыгарган актларны өйрәнүне таләп иткәнлектән, эшкуарга телефоннан җавап бирү мөмкин булмый. Бер үк төрле мөрәҗәгатьләр булмый, бигрәк тә институт республика территориясендә беренче ел эшләгәндә. Шуңа да телдән кайбер мөрәҗәгатьләрне эшкуарлар соңрак шикаять рәвешендә бирелделәр, шуннан соң аларны тикшерү буенча Вәкаләтле вәкил тарафыннан тулы күләмдә эш башкарылды: шикаять бирүче – эшкуардан кергән барлык рәсми кәгазьләр тикшерелде, вәкаләтле органнан документлар соратып алынды, вәкаләтле органның барлык аңлатуларына бәяләмә бирелде, аның гамәлләре яисә гамәл кылмавы килеп туган проблемага карата кулланып була торган законнарга туры килү-килмәве тикшерелде. Әлеге эшнең йомгаклары буенча Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьне өйрәнгәннән соң, эшкуарның хокуклары бозылуы ачыкланган очракларда, гамәл кылу ысуллары турында карарлар кабул итте.

Вәкаләтле вәкилгә озак вакытлар дәвамында проблемалары хәл ителмәгән, күп кенә органнардан эшләре кире кагылган эшкуарларның иң беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итүе табигый. Мондый мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү һәм хәл итү шактый гына күп хезмәт таләп итүен билгеләп

китәргә кирәк. Шулай да Вәкаләтле вәкилнең 2013 елда эш йомгакларында эшләрне карап тикшерүдә күп кенә уңай нәтиҗәләр бар. Әлеге бүлектә шуларның кайберләре турында сүз алып барырбыз.

**Нигезсез җинаять эзәрлекләве**

Җинаять эшләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләргә килгәндә, аларның үзенчәлекле булуын әйтергә кирәк. Алар һәрчак гаять зур күләмдә материаллар тикшерү зарурлыгы белән бәйле. Алай гына да түгел, бу материаллар белән танышу закон нигезендә чикләнгән була, һәм ул вакытта Вәкаләтле вәкилгә шикаять бирүче тапшырган документлар нигезендә, ә болар исә мөрәҗәгатьне тулы, төрле яклап һәм объектив тикшерү өчен җитеп бетми, эш йөртергә туры килә. Ул очракта Вәкаләтле вәкил эшкуарның проблемасы буенча аларның да позициясен ачыклау өчен, хокук саклау органнары белән төрлечә элемтәгә керергә мәҗбүр була.

*Махсус рөхсәтсез (лицензиясез) эшчәнлек алып барган өчен җинаять җаваплылыгына тарту омтылышы:*

Мөрәҗәгатьләрнең берсе белән эшләгәндә, лицензия мәҗбүри булган очракларда, лицензиясез эшкуарлык эшчәнлеге алып барган эшкуарны нигезсез рәвештә җинаять җаваплылыгына тарту омтылышы ачыкланды. Моңа эшкуар белән муниципаль берлек администрациясе арасында мөнәсәбәтләрнең кытыршылыгы сәбәп була. Вәкаләтле вәкил җинаять эше буенча булган материалларны анализлап, җинаять эшен тикшерүче хокук саклау органы хезмәткәре белән очрашты. Вәкаләтле вәкил җинаять кылуда шик астында булган эшкуар мөрәҗәгатен карауга керешкәндә, җинаять эшен тикшерү инде бер ел дәвам итә иде. Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, шушы ел эчендә эшкуар, квалификацияле адвокатлар ярдәме белән, төрле органнарга үзен нигезсез рәвештә җинаять җаваплылыгына тартырга тырышуларына игътибар итүләрен сорап, шактый күп шикаятьләр юллаган. Әмма әлеге омтылышлар көтелгән нәтиҗәне бирмәгән. Вәкаләтле вәкил тарафыннан кирәкле бөтен мәгълүмат тупланып, тикшерү органнарының җинаять эше кузгату буенча гамәлләре нигезсез булуга ачык дәлилләр табылгач, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуроры белән очрашты. Вәкаләтле вәкил ачыкланган барлык ялгышларны, очы очка ялганмаган урыннарны, эшкуарның җинаять җаваплылыгына нигезсез тартылуына дәлилләрне китереп, Прокурорга үз позициясен нигезләүче барлык тиешле документларны тәкъдим итте. Әлеге очрашу нәтиҗәсендә, эшкуарга карата кузгатылган җинаять эше Татарстан Республикасы

Прокуроры кушуы буенча өстәмә рәвештә тикшерелде. Соңрак эшкуарга карата кузгатылган җинаять эше, җинаять составы булмаганлыктан, ябылды.

Әгәр эшкуарларның үзләренә карата җинаять кылуда шикләнеп нигезсез эзәрлекләү алып барылуы турындагы шикаятьләрен карап тикшерүләрнең уңай нәтиҗәләре турында сүз алып барсак, Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән булган үзара хезмәттәшлеккә аеруча тукталып үтәргә кирәк. Вәкаләтле вәкил белән хезмәттәшлек турындагы беренче килешү нәкъ менә Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән төзелде. 2013 елның февраленнән Татарстан Республикасы Прокурорына тикшереп өйрәнү өчен эшкуарлар шикаятьләре буенча 13 материал җибәрелде. Аларны карап тикшерү нәтиҗәсендә җинаять эшен туктату турында 1 карар, юридик затның эшчәнлегенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы 1 карар юкка чыгарылды, җинаять эше кузгату турындагы 2 карар бетерелде, җирле үзидарә органына җир кишәрлекләрен рәсмиләштергәндә гамәлдәге законнарның үтәлмәвен булдырмау турында 1 күрсәтмә чыгарылды.

*<u>Махсус рөхсәтсез (лицензиясез) газ бүлү подстанциясен эшләтү белән бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгына тарту омтылышы:</u>*

Эшкуарның җинаять эше белән бәйле проблемасын уңай хәл итүгә завод милекчесеннән кергән мөрәҗәгатьнең Вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерелүе ачык мисал булып тора. Заводның гамәлдәге директорына карата кирпеч җитештерү өчен газ бүлү подстанциясен шартлау мөмкинлеге булган производствога лицензиясез эшләтүе вакытында законсыз эшкуарлык алып баруы (РФ ЖК 171 ст.) һәм җинаятьчел юл белән алынган акчаны легальләштерү (РФ ЖК 174.1 ст.) фактлары буенча җинаять эше кузгатылу сәбәпле, эшкуарның эшчәнлегендә кыенлыклар килеп чыга. Оешманың барлык эшчәнлеге тикшерү алып барылган чорда тулысынча туктатыла, милекче зур зыян күрә. Әлеге мөрәҗәгатьне тикшергәндә Вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерү органының позициясе бик тә тотрыксыз булуы ачыклана: тикшерү ярты ел дәвам иткән, шуңа карамастан, җинаять эше материалларында шик астына алынган эшкуарның гаебен раслардай бернинди төгаен дәлил тупланмаган. Алай гына да түгел, Ростехнадзорның заводка лицензия таләп ителмәве турындагы позициясе бар. Югары тикшерү органының әлеге фактка игътибарын юнәлтергә тырышу нәтиҗә бирмәде. Шуннан соң Вәкаләтле

вәкил, үз позициясен күрсәтеп, барлык материалларны Татарстан Республикасы Прокурорына юллады. Мөрәҗәгатьне карап тикшерү һәм Вәкаләтле вәкил карашын билгеләү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Прокуратурасы гаепләүгә нигез итеп алынган статьяларның берсе буенча эшне туктату кирәклеге турында карар чыгарды. Әмма завод директорына карата кузгатылган җинаять эшен тулысынча туктатуга ирешеп булмаганлыктан, Вәкаләтле вәкил, шикаять бирүче белән берлектә, судка тикшерү органнарының тикшерү вакытын озайту буенча гамәлләренә шикаять белән мөрәҗәгать итүе өчен кирәкле барлык материалларны әзерләде. 2013 елның декабрендә суд тикшерү органнарының башлангыч тикшерү уздыру срокларын озайту гамәлләрен законсыз дип тану турында карар чыгарды. Әлеге карарга тикшерү органы тарафыннан Татарстан Республикасы Югары судына шикаять бирелде, әмма беренче инстанция суды карары үзгәрешсез калдырылды. Эшкуар хокукларының бозылуын туктатуга ирешелде.

*Гражданнар арасында хокук мөнәсәбәтләре кысаларында эшкуарга карата җинаять эше кузгату омтылышы:*

Теге яисә бу җинаять эше кузгатылуга еш кына бер корпоротив эчендә килеп чыккан низаг, ягъни хуҗалык җәмгыятьләрендә катнашучылар яисә акционерлар арасындагы низаг сәбәпче була. Кагыйдә буларак, низагта катнашучы яклар үз конкурентларын «юлдан алып ташлауның» мондыйрак ысулларын сайлыйлар: низаглашучы якның берсе оппонент якның хокукка каршы гамәлләре белән бәйле рәвештә аңа карата җинаять эше ачуны кузгата. Әмма хокукка каршы бу гамәлләрнең характеры һичшиксез җинаятьчел булырга тиеш. Эш барышында эшкуар – бизнес хуҗаларының берсе биргән шикаятьләр белән эшләү барышында акционерларның эш алып бару тәртибе, табышны бүлү һәм директор кандидатурасы турында уртак фикергә килә алмавы нәтиҗәсендә низаг килеп чыгуы ачыклана. Әлеге низаг үсә бара, һәм якларның берсе хокук саклау органнарына бәхәсле хуҗалык җәмгыятенең «проблемалы» (ягъни кайтарып бирелми торган) дебиторлык бурычы барлыкка килү факты буенча җинаять эше кузгату турында гариза бирергә карар кыла. Тикшерү органнары әлеге «кайтарып бирелми торган» дебиторлык бурычы барлыкка килүдә гаепле генераль директорга (бәхәсле җәмгыять акционерларының берсе булып тора) карата җинаять эше кузгата. Әмма җинаять эшен кузгатуга нигез булып торган барлык шартларны җентекләп өйрәнгәннән соң Вәкаләтле вәкил бу очракта гражданнар арасында хокукый

мөнәсәбәтләрнең чагылышын ачык булуын күрсәтә: бурычның чынлап та булуы, әмма дебиторның, кайвакытта артык озакка сузылмаган кичегүләр белән булса да, аларны каплый килүе, әмма дебиторлык бурычы барлыкка килүгә нигез булган барлык алыш-бирешләрнең җәмгыять тарафыннан гадәти хуҗалык эшчәнлеге алып барылган вакытта барлыкка килүе һәм алар берничек тә җинаять эше кузгату өчен сәбәп була алмавы ачыклана. Әлеге вазгыять ачыкланганнан соң Вәкаләтле вәкил тикшерү органнары белән элемтәгә керә, аларга җинаять эше кузгатылган бәхәсле мөнәсәбәтләрнең гражданнар арасындагы килеп чыккан низаглар характерында булуы турындагы карашларын җиткерә һәм өстәмә рәвештә тикшерү органнарына үз адресына килгән мөрәҗәгать буенча сорату җибәрә. Әлеге соратуга җавап итеп тикшерү органы, җинаять составы булмаганлыктан, җинаять эше ябылу турындагы мәгълүматлы хат юллый.

Гомумән алганда, күпчелек очракта нәкъ менә корпорацияләр эчендәге низаглар Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүгә этәргеч бирә. Биредә хуҗалык бәхәсләрен, ягъни эшкуарлык эшчәнлегенең тигез хокуклы ике субъекты арасында килеп чыккан бәхәсләрне хәл итү Вәкаләтле вәкил компетенциясендә булмавын ачык аңларга кирәк. Әмма мондый бәхәсләр теге яисә бу дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары ягыннан явызларча эш кылу китереп чыгара икән, бу очракта Вәкаләтле вәкил катнашырга һәм вәкаләтле орган яисә оешма, шулай ук аның вазыйфаи затлары гаебе белән низагта катнашучы якларның берсенә карата алып барылучы гаделсезлекне туктатырга мөмкин.

Кызганыч, әмма Вәкаләтле вәкил эшкуарларның хокукларын торгызуга ирешкән, җинаять эшләренә бәйле кергән мөрәҗәгатьләрнең барысы турында да ачыктан-ачык сөйләп булмый, әмма аларны хәл итү, кагыйдә буларак, бизнесны, эшкуарның еллар дәвамында булдырылган яхшы атын, һәм, ниһаять, эшкуарлык эшенең үзен дә саклап калырга мөмкинлек бирә.

### Дәүләт органнарының хокук бозулары

Алга таба сүз административ характердагы хокук бозулар, ягъни эшкуарларның үз эшчәнлекләренә вәкаләтле органнарның һәм оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының законсыз гамәлләре яисә гамәл кылмаулары киртә булуы турындагы мөрәҗәгатьләре турында сүз барачак.

Беренче чиратта, эшкуарларның хокуклары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан бозылу очраклары турында сөйләү максатка яраклы булыр.

*Гражданнарның ташламаларга хокукы булган категориясен транспортта йөрткән өчен компенсацияләр түләүдән баш тарту:*

Пассажирларны, шул исәптән ташламаларга хокукы булган гражданнарны транспортта йөртү белән шөгыльләнүче эшкуарлар мөрәҗәгатеннән аларның чыгымнарын каплауга акча күчерү буенча бурычларын үтәмәүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы гамәлләре турында мәгълүм булды. Әлеге орган үз йөкләмәләрен бер ел дәвамында, 2012 елның сентябреннән үтәми, ә бурыч суммасы 2012 ел ахырына 14 миллион сумнан артып китә. Мөрәҗәгать материалларын өйрәнеп, Вәкаләтле вәкил республика территориясендә транспортчыларга компенсацияләр бүлү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче вәкаләтле башкарма хакимият органы җитәкчелеге белән берничә киңәшмә уздырды. Әлеге эш барышында эшкуарларга компенсацияләр түләүдән баш тарту өчен законнарда каралган нигезләр юклыгы турында уртак нәтиҗәгә киленде. Эшкуарлар, әлеге процедура өчен гамәлдә булган тәртиптә, җирле үзидарә органына кирәкле документларны тапшырдылар. Вәкаләтле министрлык тарафыннан күрсәтелгән өстәмә таләпләр мәҗбүри булмыйча, альтернатива характерында иделәр. Министрлыкның компенсация акчаларын түләү буенча бурычлары барлыгын аңлауда уртак фикергә килгәннән соң республиканың финанс министрлыгы хезмәткәрләре белән бергәләп, компенсация түләүләрнең күләмен килештерү эше башкарылды. Вәкаләтле вәкил башкарган эш нәтиҗәсендә 14 миллион сумнан артыграк компенсация суммасы, ниһаять, эшкуарларның хисап счетларына күчерелде.

*Хосусый мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә субсидияләр түләү срокларын бозу:*

Бу проблема алдагысына охшаш, аерма тик шунда: ул хосусый мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә килеп чыккан. Ябылу куркынычы алдында торган бу учреждение, ахыр килеп, барлыкка килгән кыенлыкларны хәл итүне сорап, Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итә. Шикаятьне тикшерү барышында әлеге мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе вәкаләтле органга үзенә тиешле субсидияләр суммасын исәпләү һәм күчерү өчен кирәкле барлык документларны тапшырганлыгы ачыкланды. Әмма субсидияләрне түләү мәсьәләсе, түләү өчен нинди дә булса объектив

сәбәпләр булмауга да карамастан, хәл ителми. Вәкаләтле вәкил вәкаләтле органнан кирәкле мәгълүматны алганнан соң, аны өйрәнеп, әлеге дәүләт хакимияте органы җитәкчеләре белән очрашу уздырды, акча мөрәҗәгать бирүчегә күчерелде. Әмма мөрәҗәгатьне тикшерү барышында тагын бер мәсьәлә барлыгы ачыкланды: бу – муниципаль һәм хосусый мәгариф учреждениеләренең дәүләткә ил халкы алдындагы социаль бурычын үтәүдә бертигез ярдәм итүләренә дә карамастан, аларга дәүләт ярдәме тигез күрсәтелмәү мәсьәләсе. Әлеге мәсьәләне Вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте органнары дәрәҗәсендә күтәрде, Татарстан Республикасы Президентына җиткерде, эшкуарларның хосусый мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибен яңадан карап үзгәртү кирәклеге турында эшкуарлар аргументлары яклы дәлилләр китерелде. Һәм, әйтергә кирәк, әлеге дәлилләр игътибарсыз калдырылмады һәм вәкаләтле министрлыкларга хосусый мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә җитәрлек ярдәм күрсәтелмәве белән бәйле хәлне анализларга һәм әлеге вазгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә кушылды.

*<u>Дәүләт функциясе күрсәтүнең җитәрлек дәрәҗәдә анык регламентлаштырылмавы:</u>*

Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан эшкуарлар хокуклары бозылу фактлары буенча Вәкаләтле вәкил тарафыннан уңай хәл ителгән мөрәҗәгать мисалы буларак инвалидлар өчен протезлар эшләүче оешманың мөрәҗәгатен китерергә була. Мөрәҗәгатьтә социаль яклау органнарының инвалидларны протезлар эшләүче тиешле оешмаларга җибәрү процедурасы, аның анык регламентлаштырылмавы нәтиҗәсендә коррупция куркынычы тудыруы, бер яисә берничә җитештерүче файдасына, өстәвенә һәр очракта да нигезле булмаган «өстенлек» бирелүе билгеләнә. Мөрәҗәгатьтә китерелгән дәлилләрне өйрәнү максатларында Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе белән бергәләп инвалидларга техник реабилитация чаралары бирүдә урнашкан тәртиптәге гамәл белән бәйле хәлне тикшерү эше башкарылды. Нәтиҗәдә сатып алу һәм протезлар әзерләүгә гарызнамәләрне бүлү процедураларының камил булмавы, хезмәт күрсәтү регламентлары булмавы ачыкланды.

Инвалидларга (ветераннарга) техник реабилитация чаралары бирү механизмын камилләштерү һәм күрсәтелгән товарларны (эшләрне, хезмәтләрне) сатып алуны нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатларында аларны сайлап алу функцияләре Татарстан Республикасы Дәүләт сатып

алулары идарәсенә тапшырылды. Аерым товар төрләрен (эшләрне, хезмәтләрне) сатып алу гамәлләрен башкаруның яңа регламенты килештерелде. Гарызнамәләрне бүлүгә кагылышлы мәсьәлә конкурс процедуралары йомгаклары буенча протез җитештерүче бер генә оешма билгеләнү һәм протез алырга кирәк булганда, барлык инвалидларның аңа мөрәҗәгать итәргә тиеш булуы аша хәл ителде. Элегрәк исә, протез җитештерүчеләр берничәү булганлыктан, инвалидлардан заказлар җитәрлек килмәүдән ризасызлык белдерүчеләр һәрчак була иде.

Техник реабилитация чаралары бирүчеләр белән эшләүнең яңа тәртибен аңлату максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан киңәшмә уздырылды. Анда дәүләт контрактларын үтәүчеләргә расланган регламент җиткерелде.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының инвалидларны техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын (тулы циклын) эшләү башлангычы белән чыгуын билгеләп китәргә кирәк.

*Крестьян (фермер) хуҗалыкларына грант суммалары күчерүдә тоткарлык:*

2013 елның апреленнән Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына (алга таба – КФХ башлыгы) гаилә терлекчелек фермаларына грантлар бирүгә гарызнамәләр буенча акча күчерүләрне тоткарлау белән бәйле проблеманы хәл итү юнәлешендә планлы эш алып барылды.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан дәүләт ягыннан әлеге бурычның үтәлмәве сәбәпләрен һәм масштабларын ачыклау буенча эш башланды. Мондый «финанслап бетерелмәгән» фермерлар саны алтмыш өч булып, шуларның унбише вәгъдә ителгән гарнттан бөтенләй бер сум да алмаган. Әмма Вәкаләтле вәкил алдына гаять катлаулы бурыч куелды: агымдагы 2013 елда фермерларга булган бурычны каплауга җибәрергә мөмкин булган акча республика бюджетында каралмаган булып чыкты. Шуның белән бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтү төрләре буенча исәпләүләрне төгәлләү мәсьәләсен хәл итүнең зарурлыгын һәм

кичектергесезлеген нигезләүгә юнәлтелгән уртак эш кузгатты. Вәкаләтле вәкил тарафыннан профильле министрлыклар катнашында әзерләнгән материалларны һәм тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына җибәргәч, проблеманы хәл итүгә ирешелде – кулларында грант бирү турында кул куелган килешү булган фермерлар үзләренә тиешле акчаны алдылар. Шул ук вакытта тәгаен мөрәҗәгать белән эшләү барышында аерым бер фермер проблемаларын гына түгел, бәлки мондый кыенлыкка таруларына да карамастан, Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итмәгән барлык фермерлар проблемаларын хәл итү мөмкин булды. Шул рәвешчә, гаилә терлекчелек фермаларына ярдәмгә бирелгән грантларның гомуми күләме 2013 елда 230 786,7 мең сум тәшкил итте. Гаилә терлекчелек фермаларына ярдәмгә бирелгән 230 786,7 мең сум грантларның 105 933,7 мең сумы фермерларның 2012 елгы бурычларын каплауга тотылды. Калган сумма 2013 елда барлыкка килгән бурычларны түләүгә тотылды. 135 кеше грант алды, шул исәптән 63 кешегә 2012 елгы гарызнамәләр буенча грант бирелде.

**Җирле үзидарә органнары тарафыннан хокук бозулар**

Җирле үзидарә органнары тарафыннан да законга каршы гамәлләр кылыну фактлары бар. Нәкъ менә җирле үзидарә органнарына, кагыйдә буларак, фермерлар теге яисә бу үтенеч белән мөрәҗәгать иткәнлектән, хокукка каршы мондый гамәлләр күбрәк массачыл төсмер ала. Фермерларның үтенечләре һәрвакытта да гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителми.

*Муниципаль мәгариф учреждениесенә китерелгән җиһазлар өчен түләүне кичектерү:*

Шәхси эшкуар менә ярты ел дәвамында муниципаль берәмлекнең башкарма комитетыннан муниципаль мәгариф учреждениесенә китергән 2,5 млн сумлык җиһаз өчен акча ала алмый. Муниципалитет исә, акча юклыкны сылтау итеп, аңа түләргә бик ашкынып тормый. Эшкуарның язма мөрәҗәгатьләре бернинди нәтиҗә бирми. Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итеп бер ай да үтми, муниципаль берәмлек башкарма комитеты вәкилләре белән кирәкле гамәлләр уздырыла, нәтиҗәдә эшкуар аңа тиешле акчаның 1 млн сум диярлек күләмдә беренче өлешен ала, ә тагын бер айдан бурычның калган өлеше тулысынча түләнә.

*Җир кишәрлеге бирү тәртибен бозу:*

Җирле үзидарәнең вәкаләтле органына карата җир кишәрлекләрен бүлүгә кагылышлы бирелгән шикаять аерым урын тота. Әлеге мөрәҗәгатендә эшкуар инде күптәннән бирле үзе файдалануга алырга тырышып йөргән күршесендәге җир кишәрлегенең, нинди дә булса ачык процедуралар уздырмыйча гына, башка бер затка тапшырылуы турында хәбәр итә. Әлеге мөрәҗәгатьне тикшергәндә бәхәсле җир кишәрлегенең муниципаль берәмлек территориясендә урнаштырылачак объект урынын алдан ук килештереп төзелеш өчен бирелгән булуы ачыкланды. Билгеле булганча, ул вакытка әлеге гамәл муниципаль актларда җитәрлек дәрәҗәдә ачык регламентлаштырылмаган иде, бу исә җир кишәрлекләрен бүлеп бирү гамәлләрен башкарганда конкурентлыкны чикләүгә китерә. Әлеге мәсьәлә Вәкаләтле вәкил тарафыннан фикер алышуга чыгарыла: Россия Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм тиешле вәкаләтле муниципаль берәмлек органы җитәкчесе эшкә тартылды. Әлеге эш нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлек территориясендә урнаштырылачак объект урынын алдан ук килештереп төзелеш өчен җир кишәрлеге бирү тәртибен билгеләүче регламентның яңа редакциясе әзерләнде. Хәзер исә муниципаль акттагы Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән эшкуарга аны кызыксындырган җир кишәрлеген алу гамәлләрендә катнашырга комачаулаган барлык ачык һәм төгәл булмаган нәрсәләр бетерелде.

*Җир кишәрлеген сатып алу процедураларының озакка сузылуы:*

Вәкаләтле вәкил адресына алынган шикаятьтә муниципаль орган белән закон нигезендә аңа бирелгән хосусыйлаштыру хокукыннан файдаланып җир кишәрлеген сатып алырга теләк белдергән эшкуар арасында бик озак вакытлар дәвам иткән үзара мөнәсәбәтләр тарихы тасвирлана. Төрле сәбәпләр аркасында җирле үзидарә органы вазыйфаи затлары эшкуарга җир кишәрлеген сатып алуны рөхсәт итмиләр, шуңа бәйле рәвештә, эшкуар хәтта берничә суд процессы башлап җибәрә, аларда суд эшкуарны хаклы дип табып, вәкаләтле муниципаль органга эшкуарга бәхәсле җир кишәрлеген бирергә дигән карар да чыгара. Инде бөтен мәсьәләләр суд тарафыннан хәл ителде дигәндә генә, эшкуарның хокуклары чынлап та бозылуы ачыкланган, инде бары суд карарын үтәү һәм бәхәсле җир кишәрлеген сатып алу турында шартнамә төзү генә кирәк булганда, кинәт тагын бер проблема – җир кишәрлеген сатып алу бәясен билгеләү кыенлыгы килеп туа. Бу очракта инде эшкуар, озак вакытка сузылачак суд

тикшерүләренә кереп батмас өчен, судка түгел, бәлки Вәкаләтле вәкилгә һәм прокуратурага мөрәҗәгать итәргә карар кыла. Муниципаль органның законга каршы гамәлләр кылуы ачык була. Шуңа күрә Вәкаләтле вәкил һәм прокуратура органнары компетенцияләре нигезендә чаралар күрәләр. Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органы вазыйфаи заты белән шәхсән очрашып, эшкуарның хокуклары бозылуны туктату кирәклеген нигезли. Башкарылган эш йомгаклары буенча эшкуарга җир кишәрлеген сатып алу шартнамәсе кул кую өчен җибәрелә. Гамәлдәге законнарга тулысынча туры килә торган әлеге шартнамәгә кул куйганнан соң һәм дәүләт теркәвенә алынганнан соң эшкуарның бөтен хокуклары торгызыла.

**Намуссыз конкурентлык**

2013 елда алынган күп кенә мөрәҗәгатьләр теге яисә бу рәвештә дәүләт заказы базарында намуссыз конкурентлык проблемасына кагыла. Шуңа бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасы Дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм төбәкара элемтәләр агентлыгы» дәүләт унитар предприятиесе ярдәме белән эшчәнлеге җайга салына торган заказчылар сатып алуларының ачыклыгын арттыру эше башлап җибәрде. Татарстан Республикасы Президентына эшчәнлеге җайга салына торган заказчылар сатып алуларының ачыклыгын арттыру буенча бирелгән һәм килештерелгән кайбер тәкъдимнәрнең гамәлгә ашырылуы аркасында, Татарстан Республикасының 520 компаниясе сату-алу гамәлләрендә катнашу һәм бертигез катнашу принциплары нигезендә сыйфат һәм бәяләр ягыннан көч сынашу мөмкинлеге бирелде. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының 158 фирмасы 863 млн сумга яңа контрактлар төзеде. Республика дәүләт һәм муниципаль предприятиеләренең сатып алу процедураларында кече, урта һәм эре эшкуарлар чикләнмәгән санда катнашу мөмкинлеге алды. Бу мәгънәдә Вәкаләтле вәкил тарафыннан тәкъдим ителгән карарның республикада гамәлгә ашырылуы «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар сатып алу, эш башкару, хезмәт күрсәтү турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль законда куелган максатларны тулысынча гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирде.

Чынлап та, тәгаен бер мөрәҗәгатьне карап тикшерү кысаларында Татарстан Республикасының йөзләгән, ә кайчакта меңләгән эшкуарларының проблемаларын хәл итеп булганлыктан, Россиядә моңарчы булмаган әлеге институтны төзү турындагы карар кабул итү өчен нигез булган максат бик ачык күзаллана. Әлбәттә, һәрбер мөрәҗәгатьне карап тикшерү һәм хәл итү,

авыр, ә кайчакта бөтенләй хәл ителмәслек кебек тоелган проблемага тарган нинди дә булса аерым алынган эшкуарга ярдәм итү – Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Әмма теге яисә бу мөрәҗәгать алынгач та һәрвакыт анализ ясала: республиканың эшкуарлары өчен бу проблеманың ни дәрәҗәдә таралыш алган булуы тикшерелә. Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән эшкуарның проблемасын хәл итү өчен яшерен (ә кайчакта ачык) системалы проблеманы хәл итәргә туры килгәндә, Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге шушы очракларда аеруча зур файда китерә.

Әлеге бүлектә Вәкаләтле вәкил тарафыннан эшкуарлар мөрәҗәгатьләрен уңышлы хәл итү очракларының барысы турында да сөйләнмәде, һәм моның объектив сәбәпләре бар: кайчак эшкуарлар мөрәҗәгатьләре турында артык җәелеп сөйләмәүне үтенәләр, һәм аларның теләге белән исәпләшмичә булмый. Әмма бу бүлектә яктыртылган эшләрнең эчтәлеге эшкуарлар бик еш очраша торган, аеруча таралыш алган хокук бозулар мисалы булып тора. Мондый очраклар көннән-көн кими барырга тиеш.

## СИСТЕМАЛЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2013 ел буена эшкуарлык берләшмәләренең һәм дәүләт органнарының игътибар үзәгендә Россиядә эшкуарлыкны үстерү юлында торган системалы мәсьәләләрне карау һәм хәл итү булды. Бу инде 2012 елның май аенда ук Россия Федерациясе Президенты тәкъдим иткән, Россия Федерациясендә эшлекле мохитне яхшыртуга юнәлдерелгән төрле юл карталары эшләү һәм гамәлгә кертү буенча актив эш алып бару белән дә, шулай ук эшкуарларның тагын да ныклабрак һәм ачыктан-ачык үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклавы белән дә бәйле.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан ел дәвамында Татарстан Республикасы эшкуарлары өчен системалы төстә кабатланып килүче мәсьәләләргә мониторинг уздырылды, эшкуарлардан, шул исәптән эшкуарлык берләшмәләреннән мәгълүмат тупланды. Эшкуарлардан килгән үзләрен борчыган мәсьәләләр турында мөрәҗәгатьләргә нәтиҗә ясау нигезендә, алар фикеренчә, 2013 елда Татарстан Республикасы эшкуарлары алдында килеп туган системалы мәсьәләләр дип түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк.

### I. «Юл карталарында» чагылыш тапкан мәсьәләләр

Әлбәттә, гомумироссия күләмендә ачыкланган мәсьәләләр республикабыз эшкуарларына да кагыла, шуңа әлеге бүлек кысаларында аларның аеруча кискен булганнарына гына тукталабыз.

*1. <u>Илебез җитештерүчеләренең чит ил базарларына чыга алуы белән бәйле мәсьәләләр</u>*

Кече һәм урта бизнес товарларын чит илгә чыгаруга дәүләт ярдәме кирәклеге товарларны чит илгә чыгарганда катлаулы һәм озак административ һәм фискаль процедуралар мәсьәләсе, кече һәм урта предприятиеләргә, яңа гына эшли башлаучы экспортерларга юнәлдерелгән экспортка ярдәм итүнең төбәк инфраструктурасы булмау; төп сәүдә-икътисадый партнерлар белән товарларны чит илгә чыгаруга кыенлык тудыра торган виза чикләүләре белән бәйле. Әлеге мәсьәләләрне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 29 июнендәге 1128 номерлы карары белән расланган «Чит ил базарларына чыгуга ярдәм итү һәм экспортка булышлык күрсәтү» юл картасын гамәлгә кертү нәтиҗәләре буенча 2012-

2015 еллар дәвамында хәл итү планлаштырылды. Әлеге юл картасын гамәлгә кертүнең максаты булып, экспортер-оешмаларның теркәлгән кече һәм урта предприятиеләрнең гомуми санындагы өлешен арттыру, чимал булмаган экспортның Россия Федерациясе гомуми экспортындагы өлешен арттыру һәм аңа бәяне сизелерлек күтәрү, экспортка булышлык итүнең һәркем файдалана алырлык финанс чараларын арттыру, таможня процедураларын гадиләштерү тора. Әлеге юл картасын гамәлгә кертү Татарстан Республикасы эскпортер-предприятиеләре эшчәнлегенә дә уңай йогынты ясар дип уйланыла, чөнки нәкъ менә безнең төбәк эшкуарлык өлкәсендәге яңалыклар күзлегеннән караганда, иң тиз үсүче төбәк булып санала.

2. *<u>Энергетика инфраструктурасыннан һәркем файдалана алырлык булуы мәсьәләсе</u>*

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил адресына әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгатьләр телдән дә язмача да килде. Моның шактый катлаулы һәм күпкырлы мәсьәлә булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Ул технологик кушу кагыйдәләренең (алга таба – ТК) камил булмавына, ТКның озак вакыт эшләнүенә һәм күп баскычлардан торуына, ТКга бәянең югары булуына, челтәр компанияләре эшчәнлегендә җитешсезлекләр булуга бәйле. Әлеге барлык мәсьәләләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 30 июнендәге 1144 номерлы боерыгы белән расланган «Энергетика инфраструктурасының һәркем файдала алырлык булуын күтәрү» дигән юл картасында ачык чагылыш табалар. Аларны 2012-2015 еллар дәвамында хәл итү тәкъдим ителә.

3. *<u>Төзелеш барышында катлаулы административ процедуралар мәсьәләсе</u>*

Вәкаләтле вәкилгә шәһәр төзелеше документларын әзерләүдән алып объектларны кулланышка кертү һәм милек хокукын теркәүгә кадәр төзелешне алып бару процессын гадиләштерүнең кирәклеге кебек кискен мәсьәлә булуы турында Татарстан Республикасының эшкуарлык берләшмәләреннән күп кенә хәбәрләр килде. Төзелеш тармагында эшләүче эшкуарлар, төзелешне башлап җибәрү өчен генә дә, еш кына бик күп инстанцияләр аша узарга һәм документлар тутырга тиеш була. Күп очракта әлеге каршылыклар эшкуарларга төзелеш эшчәнлеге алып бару юлында үтеп булмаслык киртәләр хасил итә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 1136 номерлы боерыгы белән расланган «Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә хокукый җайга салуны камилләштерү һәм төзелеш өлкәсендә эшкуарлык мохитен яхшырту» дигән юл картасы әлеге юнәлештәге бик күп мәсьәләләрне хәл итүгә багышланган. Әлеге юл картасын 2013-2018 елларда гамәлгә кертү каралган.

4. *<u>Инфраструктура монополияләре һәм дәүләт катнашындагы компанияләр сатып алуларыннан урта һәм кече бизнес вәкилләренең файдалана алу мәсьәләсе</u>*

*5.* Республиканың эшкуарлык берләшмәләре 2013 ел дәвамында төрле түгәрәк өстәлләр һәм киңәшмәләр барышында күп тапкырлар әлеге мәсьәләне чишү кирәклеге турында әйтеп килде. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 маендагы 867 номерлы боерыгы белән расланган «Инфраструктура монополияләре һәм дәүләт катнашындагы компанияләр сатып алуларыннан урта һәм кече бизнес вәкилләренең файдалана алуын арттыру» дигән юл картасында каралган чаралар урта һәм кече бизнес компанияләренең санын һәм продукция белән тәэмин итүнең һәм дәүләт компанияләре өчен хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә аларның өлешен арттыруга; дәүләт компанияләре өчен товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында конкурентлыкны арттыруга; урта һәм кече бизнес вәкилләре белән дәүләт компанияләренең хезмәттәшлеген оптимальләштерүгә юнәлдерелгән. Әлеге чараларны 2013-2018 елларда тормышка ашыру планлаштырыла.

6. *<u>Аерым административ процедураларның артык регламентлаштырылуы, хакимиятнең вәкаләтле органы белән хезмәттәшлек итү өчен күп вакыт һәм эшләр башкару кирәклеге мәсьәләсе</u>*

Үзенең эшчәнлеген тормышка ашырганда һәрбер эшкуар очраша торган аеруча киң таралган мәсьәләләр ул – дәүләт җайга салуының нәтиҗәле булмаган административ механизмнары. Аларны хәл итү өчен дәүләт белән эшкуарлар арасында эшчәнлек алып барганда мәгълүмати технологияләрне киңрәк куллану; дәүләт регистрлары структурасын һәм аны алып баруны оптимальләштерү; белешмәләрне дәүләт регистрларына һәм реестрларына кертү һәм әлеге белешмәләрне бирү тәртибен билгеләү тәкъдим ителә. Әлеге мәсьәләнең төп юнәлешләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 11 июнендәге 953 номерлы боерыгы белән расланган «Бизнес өчен җайга салу мохитен сыйфат ягыннан арттыру»

дигән юл картасында каралган. Әлеге юл картасын 2013-2015 елларда гамәлгә кертү планлаштырылган.

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан тагын башка юл карталары да расланды, әлеге бүлек кысаларында без, Вәкаләтле вәкилгә эшкуарлардан килгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, республика территориясендә мөһим һәм актуаль булганнарына гына тукталдык.

## II. 2013 елда очраган Татарстан Республикасы эшкуарлыгы мәсьәләләре

Шулай ук, нәкъ менә 2013 елда эшкуарларга турыдан-туры очрашырга туры килгән мәсьәләләрне дә билгеләп үтү кирәк. Әлеге мәсьәләләр, еш кына республика эшкуарлары эшчәнлегенә җитди, ә кайчакта тискәре яктан да йогынты ясаган законнарның теге яки бу нигезләмәләре үз көченә керүе белән бәйле.

### *1. Иминият кертемнәренең күләме арту*

2013 елның 1 гыйнварыннан «Мәҗбүри пенсия иминияте мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе аерым законнарына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 3 декабрендәге 243-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре үз көченә керде. Әлеге Федераль закон нигезендә шәхси эшкуарлар, адвокатлар һәм нотариуслар өчен 2013 елның 1 гыйнварыннан иминият кертемнәре бер тапкырга артты.

Иминият кертемнәрнең билгеләнгән ставкасы кискен арту тулаем Россия Федерациясе буенча да, аерым алганда Татарстан Республикасы буенча эшкуарлар санының күпкә кимүенә китерде. Салым органы мәгълүматларына караганда, 2013 елда 28 840 шәхси эшкуар һәм 2 593 крестьян-фермер хуҗалыгы башлыклары эшчәнлекләрен туктатырга карар кылды. Шәхси эшкуарлар санының шулай кинәт һәм шактый зур кимүе игътибардан читтә калмады, шул максаттан эшкуарлар берләшмәләренең 2013 елда иминият кертемнәренең күләме арту турындагы карарны каты тәнкыйтьләве нәтиҗәсендә 2014 елда иминият кертемнәре түләү тәртибе яңадан каралды. Кече эшкуарлык вәкилләре өчен иминият түләүләре артуының тискәре нәтиҗәләрен киметү максатларында мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият кертемнәре түләүнең түбәндәге тәртибе билгеләнде:

- еллык керем 300 мең сум һәм аннан кимрәк булганда, иминият кертеме хезмәт өчен түләүнең минималь күләме (алга таба – ХТМК) һәм иминият кертемнәре тарифының 12 гә тапкырланган чыгышы буларак исәпләнелә;

- еллык керем 300 мең сумнан артыграк булганда - ХТМК һәм иминият кертемнәре тарифының 12 гә тапкырланган чыгышына фактта алынган керемнең 300 мең сумга билгеләнгән зурлыктан артып киткән күләменең 1% ын кушып исәпләнелә.

2014 елда иминият кертемнәрен билгеләнгән күләмдә түләп баручы, керемнәре хисап елына 300 мең сумнан артык булмаган шәхси эшкуарлар, адвокатлар, нотариуслар һәм башка физик затлар өчен мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият кертемнәре күләме ике ХТМК буенча түгел, ә берсе буенча исәпләнелә.

Әлеге әйтеп кителгән барлык үзгәрешләр «Россия Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминияте» 2013 елның 23 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына, Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына иминият кертемнәре турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларында чагылыш тапты.

Шул ук вакытта, иминият кертемнәрен яңача исәпләү тәртибенең икътисадый яктан нәтиҗәсе барлык шәхси эшкуарлар өчен дә уңай булмады. Вәкаләтле вәкил адресына 2014 елда түләнергә тиешле иминият кертемнәренең күләме бер тапкырга артуы турында мөрәҗәгатьләр килде. Шуңа да, әлеге системалы мәсьәлә тулысынча чишелде дип әйтергә иртәрәк әле.

2. *Салым салуның патент системасын кертү*

2013 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 26 июнендәге 94-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Салым кодексының «Салым салуның патент системасы» дигән 26.5 бүлеге үз көченә керде, Россия Федерациясе Салым кодексының 346.25.1 статьясы үз чиратында үз көчен югалтты. Төп үзгәрешләр түбәндәгеләргә кагыла.

Патент йогынтысына эләгүче эшкуарлык эшчәнлеге төрләре эреләнде (69 урынына 47). Мәҗбүри исемлеккә эшкуарлык эшчәнлегенең экскурсия һәм прокат хезмәтләре кебек яңа төрләре кертелде. Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Салым кодексының 346.43 статьясы 8 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектларына эшкуарлыкның халыкка

хезмәт күрсәтүнең гомумроссия классификациясе буенча көнкүреш хезмәтенә кагылышлы өстәмә төрләре исемлеген төзү хокукы бирелгән.

Шәхси эшкуар алып барган эшкуарлык эшчәнлегенең бөтен төрләре буенча да ялланган хезмәткәрләрнең, шул исәптән гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча да, саны 15 кешегә кадәр арттырылды.

Шәхси эшкуар алырга мөмкин булган еллык керемнең минималь күләме (2013 елга 100 мең сум) һәм максималь күләме билгеләнде (2013 елга 1 млн.сум, ул Россия Федерациясе субъектлары карарлары белән арттырылырга да мөмкин).

Шулай итеп, салым салуның патент системасы куллану тәртибенә кагылышлы мәсьәләләрнең бер өлеше турыдан-туры Татарстан Республикасы законнары белән җайга салынуны таләп итте.

Татарстан Республикасы территориясендә әлеге махсус режим «Татарстан Республикасы территтprojectриясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – «65-ТРЗ номерлы ТР Законы») нигезендә кертелде. Әмма эшкуарлык берләшмәләре әзерләгән Россия Федерациясенең төрле субъектларында патент алу шартларына чагыштырма анализ Татарстан Республикасында салым салуның патент системасының эшкуарлар өчен кызыктыргыч булмавын күрсәтә. Салым органнары мәгълүматларына караганда, 2013 елның 1 ноябренә Татарстан Республикасында салым салуның патент системасын кулланучы шәхси эшкуарлар саны 881  иде, бу 2013 елның 1 гыйнварына (салым салуның патент системасы кертелү вакыты) патент хокукында салым салуның җиңеләйтелгән системасында 3 849 эшкуар эшләде.  Шулай итеп, Татарстан Республикасының 3 000гә якын эшкуары салым салуның яңа патент системасы файдалы түгел дип санап, салым салу системасын үзгәртергә кирәк дигән фикергә килде яисә бөтенләй салым салу органында эшкуар булып теркәлүдән баш тартты. Республика эшкуарлары өчен системалы булган әлеге мәсьәләне хәл итү юлларына әлеге Докладның аерым бүлеге багышланган.

### *3. Бары тик капиталь биналарда, корылмаларда сәүдә итүне оештыру таләпләренең үз көченә керүе*

2013 елның 1 гыйнварыннан  авыл хуҗалыгы базарлары һәм авыл хуҗалыгы кооператив базарларыннан тыш, кайда урнашкан булуларына карамастан, базарларны һәм федераль әһәмияткә ия Мәскәү һәм Санкт-

Петербург шәһәрләре территорияләрендә урнашкан башка ваклап сату базарларын җиһазландыру һәм төзү «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 30 декабрендәге 271-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән төп таләпләрне мәҗбүри саклаган хәлдә идарәче компанияләр тарафыннан тормышка ашырыла. Шул ук вакытта, 2013 елның 1 гыйнварыннан авыл хуҗалыгы базарлары һәм авыл хуҗалыгы кооператив базарларыннан тыш, кайда урнашкан булуларына карамастан, базарларда һәм федераль әһәмияткә ия Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре территорияләрендә урнашкан башка ваклап сату базарларында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү) буенча эшчәнлеген идарәче компанияләр бары тик биналарда, корылмаларда гына тормышка ашырырга хокуклы.

Әлеге гамәлләрнең төп максаты – базарлар эшчәнлегенең һәркемгә аңлаешлы булуын һәм нәтиҗәлелеген арттыру, ә бу үз чиратында конкурентлылык принципларының аларга күбрәк йогынты ясавына, җитештерүчеләрнең һәм җитештерү берләшмәләренә базарларга керү мөмкинлеген җиңеләйтергә, базарны, чын мәгънәсендә, югары мәдәниятле сәүдә итү ноктасына әверелдерергә ярдәм итәчәк. Закон чыгаручының карашы шундый.

Инде 2006 елда ук ваклап сатуны оештыру тәртипләренә таләпләр билгеле һәм аларны кертүнең котылгысыз булуы әйтелсә дә (2013 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге таләпләрне кертү соңгы тапкыр 2009 елның июлендә кичектерелде), эшкуарлык берләшмәләре тарафыннан әлеге мәсьәләне кабул итү һәм аның турында фикер алышу бик зур шау-шу куптарды.

2013 елның 24 гыйнварына Россия Федерациясе Дәүләт Думасына «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 30 декабрендәге 271-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясына үзгәрешләр кертү буенча биш закон проекты карауга кертелде.

Әлеге үзгәрешләрнең төп асылы шунда ки – капиталь биналар, корылмалар турында таләпләрне кертүнең вакытын озайту (01.01.2015 кә кадәр һәм 01.01.2020 гә кадәр) яисә әлеге статьяны бөтенләй юкка чыгару. Таләпләрне кертү вакытын билгеләүне Россия Федерациясе субъектларына тапшыру турында да тәкъдимнәр бар.

Әлеге вакытка кадәр бер закон проекты да беренче укылышка кертелмәде, бәлки алар 2014 елгы язгы сессиядә фикер алышуга кертелер.

*4. 670 кВттан артык көчәнешкә тоташтырылган предприятиеләргә кагылышлы электр энергиясе өчен түләүне исәпләүнең яңа тәртибен кертү*

2013 елның июленнән «Электр энергиясен куллануны тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү режимы буенча электр энергиясен ваклап сату базарлары эше турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары нигезендә 670 кВттан артык көчәнешкә тоташтырылган предприятиеләргә кагылышлы электр энергиясе өчен түләүне исәпләүнең яңа тәртибе кертелде.

Әлеге яңа тәртипкә Вәкаләтле вәкил тарафыннан анализ ясалды. Исәпләүләр буенча, 2013 елның июленә Татарстан Республикасының кайбер эре кулланучыларның электр энергиясе өчен түләүләре 40% ка артты, бу, ихтимал, куллану графигының тигез булмавы белән аңлатылды. Әгәр дә предприятиеләрдә җитештерү атнаның бары тик эш көннәрендә генә, көндез алып эшләсә, электр энергиясен күпләп сату базарында сатып алу бәясе 50 % ка җитәргә мөмкин, чөнки нәкъ менә эш көннәрендә көндез күпләп сату базарында электр энергиясенә иң югары бәя була.

2013 елда эре кулланучылар өчен электр энергиясенә бәянең артуына түбәндәге факторлар йогынты ясады:

- ирекле базарда электр энергиясен күпләп сатып алу бәясе артуы (2012 ел өчен уртача һәм 2013 елның 8 ае өчен 9%ны тәшкил итте);
- электр энергиясе өчен тарифларны план буенча яңадан карау (10-15%ка артуга китерде);
- беренче һәм икенче бәя категорияләре өчен исәпләү кагыйдәләре буенча 670 кВттан артык көчәнешкә тоташтырылган кулланучылар өчен исәпләр ясап булмау сәбәпле, электр энергиясе өчен түләүне исәпләүнең яңа тәртибен кертү (20%ка кадәр).

Шул ук вакытта тагын бер фактны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы территориясендә «Электр энергиясен куллануны тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү режимы буенча электр энергиясен ваклап сату базарлары эше турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары үз көченә кергәнче үк, электр энергиясеннән кулланган өчен түләүләре күпләп сатып алу базарында электр энергиясен сатып алу бәясен билгеләүче «ике ставкалы» формуланы файдаланып исәпләнүче предприятиеләр дә бар иде. Моннан тыш әлеге предприятиеләр электр энергиясен тапшыруда да ике ставкалы тарифтан файдаланалар һәм алар алдагы чорда үзләренең электр энергиясеннән

күпме файдаланачакларын планлаштыра алалар. 2013 елның июленнән алар өчен электр энергиясенә түләү тулаем алганда 9-10%ка артты һәм бу күпләп сату базарында электр энергиясе өчен бәянең һәм электр энергиясен тапшыру өчен тарифның күләме артуы белән бәйле иде.

Анализ ясау һәм эшкуарлык берләшмәләре белән фикер алышулардан чыгып, килеп туган әлеге хәлдән чыгу буенча аерым тәкъдимнәр формалаштырылды.

Беренчедән, заманча күпфункцияле исәпләү приборы кую.

Икенчедән, шуны да истә тотарга кирәк, әгәр дә иң күп йөкләнеш вакытында югары көчәнештән баш тартсаң, сәгатьләп исәпләү приборы куллану күпкә файдалырак була. Көчәнеш үзеннән-үзе эш көненең бер сәгате кебек билгеләнә. Шулай итеп, электр энергиясе өчен 15 процентка отышлырак бәя белән түләргә була.

Өченчедән, бер үк вакытта 670 кВттан артык көчәнешне тоташтыруның максатка ярашлы булуын да карарга кирәк. Бәлки, җитештерүнең ихтыяҗларын анализлаганнан соң, көчәнеш куллануны киметү мөмкин булыр, ә бу үз чиратында исәпләүләрнең яңа тәртибен кертү кирәклеген юкка чыгарачак.

Дүртенчедән, электр энергиясен көн дәвамында куллану графигын тигезләргә кирәк, бу вакытта кичке һәм иртәнге сәгатьләрдә электр энергиясе куллану өчен булган бәя тулаем электр энергиясе өчен түләүнең кимүенә китерәчәк (җитештерүдә мондый мөмкинлек булган очракта).

Бишенчедән, иң күп йөкләнеш вакытында электр энергиясен резервлы куллануга күчү һәм шулай итеп иң күп йөкләнеш вакытында кулланылучы көчәнешнең күләмен киметү максатларында, электр энергиясен куллануның альтернатив ысулларына (газ пешкәкләре җайланмалары һ.б.) күчү мөмкинлеген карау тәкъдим ителде.

Алтынчыдан, электр энергиясен куллануны планлаштыру кирәклеген күз алдында тотучы югарырак классына (5 һәм 6) күчү мөмкинлеген карау тәкъдим ителде. Әлеге чара үзеннән-үзе электр энергиясе өчен түләүнең кимүенә китерәчәк, чөнки әлеге кулланучылар классы өчен электр энергиясенең күпләп сатып алу бәясе түбәнрәк.

## *5. Файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кисәкләре*

Гомум милектә булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир участокларын файдалану мәсьәләсе – авыл хуҗалыгы тармагында иң кискен мәсьәләләрнең берсе булып санала. Ачык чыганаклардан алынган

мәгълүмат буенча, Россия Федерациясендә җир кишәрлекләренең 25 миллион гектары бернинди дә документлар рәсмиләштермичә генә файдаланыла. Моннан тыш, җир кишәрлекләренең зур өлеше максатка ярашлы итеп кулланылмый. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү максатында гамәлгә булган законнарда алга таба аларны гражданнарга бирү һәм рациональ куллануны тәэмин итү өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен муниципаль милеккә күчерү тәртибе билгеләнгән. Ләкин җирле үзидарә органнары хуҗасыз җирләрне муниципаль милеккә күчерүнең әлеге механизмыннан нәтиҗәле файдаланмый.

Теркәлгән крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) башлыклары саны кимүе сәбәпле, Татарстан Республикасы территориясендә әлеге мәсьәләләр аеруча мөһим була бара. Шулай итеп, 2001 елдан алып теркәлгән КФХ саны ике тапкырга кимеде. Шул ук вакытта, шуны да билгеләп үтү кирәк, 2011 елдан 2012 елга кадәр КФХ кулланышындагы җир кишәрлекләре күләме кимеде, бары тик 2013 елда аның аз гына артуы күзәтелә (1 нче таблицаны кара).

1 нче таблица

| АТАМАСЫ | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 елның гыйнвар–сентябре |
|---|---|---|---|---|
| Салым органнарында теркәлгән яисә яңадан теркәү узган крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыклары саны, кеше | **19 245** | **10 223** | **6 817** | **5 112** |
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе белән шөгыльләнүче һәм җир кишәрлеге булган, аңа хокуклары законда билгеләнгән тәртиптә (Росреестр мәгълүматлары буенча) теркәлгән крестьян (фермер) хуҗалыклары саны | **2524** | **2533** | **2597** | **2670** |
| Аларга бирелгән җир кишәрлекләре мәйданы, мең.га (Росреестр мәгълүматлары буенча) | **300,0** | **269,9** | **266,2** | **271,1** |

Җирнең Татарстан Республикасы крестьян (фермер) хуҗалыклары, фермерлары өчен төп җитештерү чарасы булуын истә тотсак, авыл хуҗалыгы кулланышындагы җир участокларын нәтиҗәле куллану үз хуҗалыкларын оештыру һәм үстерү өчен аларга мөһим этәргеч булып тора.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматлары буенча 2014 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы территориясендә **445,2 мең га файдаланылмаучы җир кишәрлекләре** ачыкланган. Шул ук вакытта, **әлеге файдаланылмаучы җирләрнең бары тик 209,09 мең га буенча гына** суд карары бар, алар әлеге җир кишәрлекләрен натурада аерып алып, аннары аларны муниципаль берәмлекнең милке итеп теркәргә һәм тулы күләмдә кулланышка кертергә мөмкинлек бирә. Шулай итеп, **гомуми мәйданы 236, 11 мең га булган җир кишәрлеге** (бу сан хәзерге вакытта КФХ милкендә булган җир участокларының гомуми мәйданына туры килә – 1 нче таблицаны кара) **кулланышка кертелә алмый**, КФХ җитештерүе өчен тулы кыйммәтле чара булып хезмәт итә алмый, чөнки мондый җирләрне муниципаль милек итеп теркәгәнгә кадәр, озак вакытка (1 елдан артык) КФХна бирү мөмкинлеге каралмаган.

## *6. Җир кишәрлекләре исәбенә җир участоклары бүлеп бирү*

Авыл хуҗалыгы кулланышындагы җир участокларын файдалану кебек системалы мәсьәләне тикшерүне дәвам итеп, җир кишәрлекләре исәбенә җир участоклары бүлеп бирү мәсьәләсен аерым карап үтү кирәк.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгыннан җир кишәрлекләрен натурада бүлеп бирү сәбәпле дәүләт теркәве узган җир участоклары мәйданы турында белешмә сорап алды. Шул вакытта бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендә милекчеләрнең аерымланган җир кишәрлекләрен рәсмиләштерүен мониторинглауны беркем дә алып бармавы ачыкланды.

Кайбер КФХ башлыклары белән турыдан-туры аралашканнан соң, җир кишәрлеге исәбенә җир участогын рәсмиләштерү барышында кыенлыклар җир кишәрлекләре милекчеләренең гомуми җыелышында җир участогы чикләрен килештергәндә, шулай ук ызан салу эшләре үткәргәндә килеп чыгуы билгеле булды. Шулай итеп, хокукларны теркәү мәсьәләсенең эшләнеп бетмәве нәтиҗәсендә, Татарстан Республикасында гомуми мәйданы 1 992 900 га булган җир кишәрлекләрен бүлеп бирү процессын суза килү сәбәпле, җир участокларының шактый зур өлеше шулай ук озак вакытка исәпләнгән нигездә (1 елдан артык вакытка) КФХ өчен файдаланыла алмый. Хәзерге вакытта Вәкаләтле вәкил тарафыннан әлеге системалы мәсьәләне чишү өчен тәкъдимнәр эшләнә.

*7. Коррупция*

Россия эшкуарлары кече һәм урта бизнесның үсешен һәм киңәюен тоткарлаучы төп фактор дип коррупцияне атый. 1990 елларда – 2000 еллар башында Россия эшмәкәрләре көндәшләре алдында өстенлекләрен күрсәтү өчен еш кына ришвәт бирделәр, бу аларга түрәләрнең теге яки бу хокук бозуларга күз йомуын, рөхсәт кәгазьләре алуны тизләтү һәм башкалар өчен кирәк булды. Соңгы берничә елда экспертлар фикеренчә, динамика уңай якка үзгәрде, әмма әлеге мәсьәлә әһәмиятен югалтмый. Әлеге катлаулы мәсьәлә икътисадый үсешне тоткарлый, җитештерүнең кимүенә китерә, эшкуарлыкка үсәргә комачаулый.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2012-2014 елларга Коррупциягә каршы комплекслы республика программасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты коррупция турында халык һәм эшкуарлар фикеренә, коррупциянең торышына, коррупциягә китерүче факторларга социологик тикшеренү үткәрде.


Сораштыруда 1505 Татарстан Республикасының кече һәм урта предприятиеләр җитәкчеләре, шәхси эшкуарлар катнашты. Сораштырылган эшкуарларның төп өлеше – юридик затлар (82,7%), калганнары (17,3%) – юридик зат белеме булган эшкуарлар. Сораштыруда катнашкан кече һәм урта бизнес вәкилләренең һәр дүртенчесе эшкәртүче производствода (33%) эшчәнлек алып бара. Респондентларның 23%ы – сәүдә өлкәсендә, 12%ы – күчемсез милек белән операцияләр, аренда һәм хезмәт күрсәтү өлкәләрендә, 9% ы – авыл хуҗалыгы тармагында, 9% ы – төзелештә эшли. Шулай ук транспорт һәм элемтә өлкәсе, гостиница һәм рестораннар, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм финанс эшчәнлеге тармаклары вәкилләренең фикере дә исәпкә алынды.

Дәүләт заказын урнаштыру вакытында коррупция күренешләрен 4,3% эшкуар, контрольдә тоту һәм рөхсәт бирүче органнар тарафыннан янауларны – 3,7% ы билгеләп үтте.

| АТАМАСЫ | 2013 ел (%) |
|---|---|
| Салым салуның югары дәрәҗәдә булуы | 62,3 |
| Икътисадый тотрыксызлык | 35,3 |
| Дәүләт тарафыннан ярдәмнең булмавы | 16,0 |
| Бюрократик киртәләр | 13,0 |

| | |
|---|---|
| Дәүләт заказын урнаштыру вакытында коррупциячел күренешләр | 4,3 |
| Контрольдә тоту һәм рөхсәт бирүче органнар тарафыннан янаулар | 3,7 |


2013 елда эшкуарларның 14,9%ы коррупциягә юлыкты. Шул ук вакытта 2009 елдан 2012 елга кадәр коррупцияле килешүләрдә катнашырга әзер булган эшкуарлар саны артуы күзәтелә (42,5% тан 47,6%га кадәр). Әмма 2013 елда ришвәт бирергә әзер булган бизнес вәкилләре саны 39,8%ка кадәр кимеде.




Тикшерүләр күрсәткәнчә, эшлекле даирәдә ришвәтнең уртача күләме 140 мең сум тәшкил итә.

Эшкуарлар үзләренең бизнесына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә йогынты ясауның формаль булмаган чараларына мөрәҗәгать итә. Сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтте, эшкуарлар формаль булмаган түләү ысулларын контрольдә тоту органнары белән сорауларны чишү вакытында аеруча еш кулланды (40,8%). Моннан тыш,  яңа эш ачканда (16,5%), җир участогы алганда (11,7%), дәүләт органнарыннан ташламалы кредитлар алганда (10,7%), дәүләт заказы алган вакытта (10,7%). Йогынты ясауның формаль булмаган ысуллары ярдәмендә тагын салым отчетлары (8,7%) һәм кирәк булган суд карарлары мәсьәләләре (5,8%) хәл ителә.

**Үткән ел дәвамында эшкуарлар эшкуарлык эшчәнлеге алып барганда йогынты ясауның формаль булмаган ысулларын кулланып хәл итәргә мәҗбүр булган мәсьәләләр (сораштырылган затлар санынннан процентларда)**




Сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, респондентларның зур өлеше (2013 елда 59,3 %) дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары белән килешүләр төзегәндә ришвәт таләп итү күренеше белән очрашмавы турында белдерде. Сораштырылганнарның  33,4 % ы шулай ук бу турыда бернәрсә дә белми. Коррупциячел күренешләргә юлыккан респондентлар 7,3% ны тәшкил итә.

Бизнес вәкилләре фикеренчә, түрәләргә ришвәт буларак килешү бәясенең ун проценты бирелә (49,1%). 11,1% респондентлар ришвәтнең күләме килешү бәясенең биштән бер өлешен тәшкил итәргә мөмкин дип саный.




Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 2015-2020 елларга коррупциягә каршы тору программасы эшләнә. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил әлеге Программа проектын эшләү буенча эш төркеме составына керә.

*8. Салымнарны чамадан тыш контрольдә тоту*

Күп кенә эшкуарлар һәм экспертлар салымнарга контрольнең чамадан тыш зур булуы шулай ук бизнесны үстерүгә һәм киңәйтүгә зур каршылык булып тора дип саный. «Күпчелек»тән аз гына аерылып китсәң, бик тиз салым органнарының игътибар үзәгенә эләгергә мөмкин. Эшкуарлардан алынган мәгълүматларга караганда, бу вакытта салым органнары бик кырыс һәм хокук бозуларның күләменә туры килмәүче гамәлдәге законнар белән билгеләнгән эшчәнлеген алып бара. Безнең Pro Bono эксперт китергән очрак моның ачык мисалы булып тора, ул вакытта «0» декларация эшләп китермәгән өчен ярты елдан артык эшкуарның исәп счеты эшләмәде.

Әлеге системалы мәсьәлә кысаларында закон белән нигезләнгән «салым файдасы» дигән төшенчәнең булмавы мәсьәләсен ассызыклап үтәргә кирәк. Әлеге төшенчә намуслы салым түләүчеләрне намуссызлары арасыннан анык кына аерылып алырга һәм шулай итеп күпчелек эшкуарларга салымны кире кайтаруга яисә салым органнары салымнар өлкәсендә тикшерүләр вакытында табышка салым салынганда тотылган акчаларны исәпкә алуга хокукларын яклау мөмкинлеге бирәчәк.

Россия Федерациясе Президенты башлангычы белән салым өлкәсендә хокук бозулар буенча җинаять эшләре кузгату тәртибенә кагылышлы төзәтмәләр яссылыгында әлеге мәсьәләләрнең әһәмияте тагын да арта. Бюджетка түләнә торган салымнарның күләмен киметү максатында салымнарын намус белән яки намуссыз түләүчеләр арасында анык кына чикнең булмавы, хокук саклау органнарына субъектив карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта Вәкаләтле вәкил әлеге ачыкланган системалы мәсьәләне чишү өчен тәкъдимнәр эшли.

*9. Хокук саклау органнары тарафыннан Россия Федерациясе Җинаять кодексында «эшкуарлык» буенча яңа статьялар кертелүгә, шулай ук оператив-эзләү чараларын уздыруның билгеле бер тәртипләренә бәйле яңалыкларны теләмичә генә куллануллары*

2012 елның ноябрендә үк җинаять һәм җинаять-процессуаль законнарга тиешле үзгәрешләр кертелүгә дә карамастан, бүгенге көндә кадәр әлеге үзгәрешләр тиешле махсус вәкаләтле органнар тарафыннан теләп һәм актив кулланыла дип әйтә алмыйбыз. Әлегә кадәр эшкуарлар хокук саклау органнарына шикаятьләр белән мөрәҗәгать итәләр, аларга карата җинаять эшләре махсус «икътисадый» статьялар буенча түгел, ә «мошенниклык» кебек гомуми статьялар буенча кузгатыла, биредә катлаулырак санкция салына, шулай ук тикшерү эшләре алып бару һәм гаепләнүчене кулга алу тәртибе гадирәк була, болар барысы да эшкуарлык эшчәнлеген туктатып торырга мәҗбүр итә, ә махсус «эшкуарлар» статьялары буенча җинаять эше кузгатылганда, эшкуарлар үз эшчәнлекләрен дәвам итәләр.

Әлеге проблема амнистия процессында да үз ролен уйный, чөнки амнистияне бары тик «эшкуарлык» статьялары буенча гына кулланырга ярый. Шулай итеп, «мошенниклык» кебек гомуми статьялар буенча җинаять эше кузгалтылган эшкуарга амнистия куллану да мөмкин булмый. Аларга квалификацияләрен алмаштыру буенча озын-озак юл үтәргә туры килә, ләкин вәкаләтле органнар мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасында квалификацияләрен үзгәрткәннән соң, амнистия акты кертелүнең бөтен чорында, бары тик бер эшкуарга карата гына амнистия кулланылды.

Әлеге мәсьәләне чишү юлында Вәкаләтле вәкил тарафыннан эшләнгән эшләр турында әлеге Докладның киләсе бүлегендә сүз алып барылачак.

*10. Салым йөкләмәләренең югары булуы, законнарга гел үзгәрешләр керү, финанс ресурсларының җитәрлек булмавы, икътисадый тотрыксызлык*

Йомгак ясап, республиканың барлык эшкуарларын борчый торган мәсьәләләр турында да әйтеп китмичә булмас. Алар – салым йөкләмәләренең югары булуы, законнарга гел үзгәрешләр керү, финанс ресурсларының җитәрлек булмавы, икътисадый тотрыксызлык. Әлеге

мәсьәләләр барысы да Вәкаләтле вәкилгә таныш, рәсми дәрәҗәдә еш тикшереләләр һәм юл карталарын гамәлгә кертү, шулай ук инде алда әйтеп үтелгән мәсьәләләр яссылыгында алар акрынлап кына чишелүгә таба баралар. Әмма дә ләкин аларны чишү конкрет бизнес вәкиле, конкрет эшкуар сөйләве буенча, теге яисә бу мәсьәлә тагын да ачыграк итеп күренгән конкрет очраклардан башка мөмкин түгел. Бары тик шул вакытта гына Вәкаләтле вәкил эшкуарга нәкъ менә үзенең билгеләнгән юнәлеше буенча алга хәрәкәт итү өчен кирәк булган мәсьәләне аңлый һәм чишә алачак. Эшкуардан килгән мәсьәләне чишү теге яки бу федераль актка үзгәрешләр кертү белән бәйле булган очракта, әлеге тәкъдимнәр формалаштырыла һәм Вәкаләтле вәкил бу мәсьәләне чишү өчен кирәкле барлык вәкаләтләре булган Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил адресына җибәрә.

## АМНИСТИЯ

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2013 елда икътисадый амнистия – икътисадка кагылышлы статьялар буенча хөкем ителгән затларны ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү буенча эше аерым блок булыр тора.

2013 елның 4 июлендә Россия Федерациясе Дәүләт Думасының «Амнистия игълан итү турында» 2013 елның 2 июлендәге карары законлы көченә керде (2559-6 ДД, 2013 елның 2 июленнән).

Амнистия турында карар кабул ителгәннән соң, Вәкаләтле вәкил тарафыннан әлеге амнистия турындагы карарны гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар җитәкчеләре белән очрашулар уздырылды. Очрашу Татарстан Республикасы прокуратурасында оештырылды. Россия Федерациясе Дәүләт Думасының «Амнистия игълан итү турында» 2013 елның 2 июлендәге карарын гамәлгә ашыру тәртибе, әлеге карар кабул ителгән вакытка ничә кеше амнистиягә эләгүе мөмкин булу турында, амнистия актын кулланганда барлыкка килүе мөмкин булган кыенлыклар турында фикер алышынды. Моннан тыш, Вәкаләтле вәкил җитәрлек дәрәҗәдә ачык формалаштырылмаган «проблемалы» нигезләмәләр буенча фикер алышуны тәкъдим итте. Амнистия турындагы карарның беренчел тикшерү органнарында производствода булган җинаять эшләре буенча узучы зыян күргән затларга милекләрен кайтарып бирү йә (яисә) зыяннарын каплау турындагы бишенче пункты үтәлү тәртибе шушындый мәсьәләләрнең берсе булды. Биредә зыян бөтенләй булмау, яисә мондый зыян җинаять эше кузгатылган конкрет физик зат тарафыннан түгел, бәлки юридик зат тарафыннан китерелгән булуы турындагы мәсьәлә килеп чыга. Моннан тыш, зыянның күләме ничегрәк билгеләнүе турындагы мәсьәлә күтәрелде. Еш кына бу зыян шикаять бирүче сүзләренә яисә җинаять эше кысаларында уздырыла торган экспертизага нигезләнеп билгеләнә. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормалары буенча зыянны каплау йөкләмәләре законлы көченә кергән хөкем карары яисә суд карары нигезендә барлыкка килә. Әлеге суд карары граждан–хокук эшләре тәртибендә чыгарыла, бу очракта суд затның зыян китерүдә гаебен, аның күләменең нигезле булуын, шулай ук зыян китерүче гамәлләре белән килеп

чыккан зыян арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше барлыгын танылган дип таба.

Киңәшмәдә Вәкаләтле вәкил тарафыннан амнистия куллану тәртибе мәсьәләләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләр алынганда, әлеге мөрәҗәгатьләрне тиешле вәкаләтле орган белән бергәләп карау, һәм шикаять бирүчеләр өчен мөмкин булганча кыска вакытта хәл итү турында килешүгә ирешелде.

Моннан тыш, республика территориясендә амнистия буенча җәмәгатьчелек омбудсмены – Ногманов Рафил Габдерәфыйк улы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары – билгеләнде. Аның белән бергәләп, 2012 елның 12 сентябрендә Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Дәүләт Думасының 2013 елның 2 июлендәге амнистия игълан итү турындагы карарын гамәлгә ашыру тәртибе мәсьәләләре буенча матбугат конференциясе уздырды.

Татарстан Республикасы территориясендә амнистияне гамәлгә ашыру дәвамында Вәкаләтле вәкил адресына бары бер эшкуар мөрәҗәгать итте. Әлеге мөрәҗәгать аңа карата нәкъ менә шул амнистия актын кулланудан баш тарту сәбәпле бирелгән иде. Хәзерге вакытта әлеге мәсьәлә гомуми юрисдикция судында тикшерелә.

Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең аз булуы Татарстан Республикасы территориясендә гомумән алганда актның үтәлүе моңа кызыксынган эшкуарларның нинди дә булса кыенлыклар кичермәве турында сөйли.

2014 елның 3 февраленә аларга карата Россия Федерациясе Дәүләт Думасының «Амнистия игълан итү турында» карары (2559-6 ДД, 2013 елның 2 июленнән) кулланылган затлар саны бөтен Россия буенча 2314 кешегә җитте.

Амнистиягә эләккән кешеләр арасында хөкем ителгән, җинаять җәзасыннан азат ителгән затлар белән бергә, тикшерү этабында җинаять эзәрлекләве туктатылган затлар да бар иде. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы кабул иткән карар нигезендә амнистия Россия Федерациясе Җинаять кодексының 146, 147, 159.1, 159.4, 171, 171.1, 172, 173.1, 173.2, 174, 174.1, 176, 177, 178 – 1 өлеш, 178 – 2 өлеш, 180, 181, 191, 192, 193, 194 – 2

өлеш, 194 – 3 өлешенең «а» пункты, 195, 196, 197, 198, 199, 199.1, 199.2 статьяларында каралган җинаятьләр өчен беренче тапкыр хөкем ителгән затларга, әгәр дә бу затлар милекне кайтарып бирү йә (яисә) зыяннарын каплау йөкләмәләрен үтәсәләр, карата кулланыла.

Амнистия керү җинаять турындагы законнарны 2009 елдан бирле планлы рәвештә гуманлаштырылу эшенең дәвамы булды. 2012 елның декабрь башында «Россия Федерациясе Җинаять кодексы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 207-ФЗ номерлы Федераль законны кабул итү эшкуарлар өчен үтә әһәмиятле вакыйга булды. Әлеге үзгәрешләр тупланмасы – икътисад өлкәсендәге җинаятьләргә кагылышлы законнарны гуманлаштыру эшендә дүртенчесе. Беренче 3 тупланма ярдәмендә хокук саклау органнарының властьтан законсыз файдалануларына киртә кую мөмкин булды. Аерым алганда, эшкуарны башлангыч тикшерү барышында кулга алу тыелды. Хәзер бу чынлап та эшли. 2012 ел үзгәрешләр тупланмасы белән Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясына (мошенниклык) гына түгел, гомумән Россия Федерациясе Җинаять кодексына үзгәрешләр кертелде. Барлыгы 37 үзгәреш кертелде, аларны дүрт блокка бүлергә мөмкин булыр иде.

Беренче блок – РФ ҖК 159 статьясына үзгәрешләр. Яңа редакциядә, мошенниклык турындагы төп статьядан тыш, тагын алты состав кертелде: кредит өлкәсендә, түләүләрдән (пособиеләр, компенсацияләр, башка социаль түләүләр) файдаланган вакытта, түләү карталары файдаланып, эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә, иминиятләштерү өлкәсендә һәм компьютердагы мәгълүматлардан файдалану өлкәсендә мошенниклык. Әмма хәзерге вакытта башлангыч тикшерү органнары тарафыннан җинаять җаваплылыгына тартылучы затларның гамәлләре күпчелек очракта РФ ҖК 159 статьясы буенча квалификацияләнә. Затның факттагы гамәлләре турыдан-туры эшкуарлык эшчәнлеге алып бару белән бәйле. Бизнес өчен төп үзгәреш – көнкүреш мошенниклыгын эшкуарлык мошенниклыгыннан аерып кую мөмкинлеге булды. Хәзер эшкуарлык мошенниклыгы алдан уйлап шартнамә йөкләмәләрен үтәмәү буларак билгеләнә. Элегрәк исә бу йөкләмәләрне гомумән үтәмәү буларак кына билгеләнә иде. Икътисадый җинаятьләр өчен җәза икътисадый яссылыкка күчерелергә тиеш.

Икенче блок – Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 20 статьясына төзәтмәләр кертү. Хокук саклау органнарына зыян күргән якның гаризасыннан башка эшкуарларга каршы җинаять эшләре кузгатуны

тыюга кагылышлы үзгәрешләр кертелде. Биредә бер чыгарылма бар: бу – дәүләткә зыян китерү очрагына карамый.

Өченче блок – Россия Федерациясе Җинаять кодексының 303 статьясына хокук саклау органнарына оператив эзләү эшчәнлеге йомгакларын фальсификацияләгән өчен җаваплылыкка тартуга кагылышлы үзгәрешләр. Хәзер кодекста мондый гамәлләр өчен 300 мең сумга кадәр штраф һәм 4 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

Дүртенче блок бизнес хуҗаларына һәм вәкилләренә алардан алына торган документларның күчермәләрен ясау мөмкинлеге бирә. Бизнес өчен яхшы хәбәр бу, чөнки моңа кадәр җинаять эше кузгатылу эшнең тукталуына һәм бөлгенлеккә китерә иде.

Законнарны йомшарту буенча планлы эш алып бару кече һәм урта бизнес өлкәсендә үсешкә ярдәм итүгә, бизнеска басым ясауны һәм килеп чыгуы мөмкин булган куркынычларны киметүгә юнәлтелгән.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЭШКУАРЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕН АЛЫП БАРУ ШАРТЛАРЫНА БӘЯЛӘМӘ

Татарстан Республикасында 2013 елда эшкуарлык эшчәнлеге алып бару шартларына бәяләмә бирү экспертлык бәяләмәсе булып тора һәм 2013 елда алынган эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләрен анализлау йомгакларына, шулай ук эшкуарлык үсешенең эшкуарлар, экспертлар, җәмәгать оешмалары вәкилләреннән сораштырулар уздыру барышында ачыкланган системалы проблемаларын анализлауга нигезләнә.

Бу бүлектә эшкуарлар юлыккан аеруча четерекле мәсьәләләрнең бер өлеше генә каралды. Бу бүлектә коррупция, квалификацияле кадрлар җитешмәү, тарифларны җайга салу, салымнарның югары булуы, дәүләт органнары тарафыннан контроль-күзәтчелек чаралар уздырыла һәм башка шундый мәсьәләләр каралмады. Бу мәсьәләләр «Системалы мәсьәләләре» дигән бүлектә каралды.

Doing Business Бөтендөнья Банкының халыкара рейтингында 2014 елда Россия Федерациясе 20 позициягә күтәрелде һәм 92 нче урынга чыкты.

Россия эшкуарлык алып бару шартларын яхшыртуга юнәлтелгән реформаларны аеруча актив уздырган илләр арасыннан берсе булды.

Бу реформалар яңа предприятие ачу, төзелеш проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле рөхсәт кәгазьләренең һәм яңа бинаны теркәү, электр энергиясеннән файдалану процедуралары, шулай милекне теркәү өчен сарыф ителгән вакытның кимүе һ.б. мәсьәләләргә кагылды. Россиядә халыкара сәүдә алып бару шулай ук гадиләштерелде. Салым түләү буенча Россия 64 урыннан 56 урынга күтәрелде (бер ел элек әлеге критерий буенча Россия берьюлы «41 басманы сикереп узды»). Гомуми салым салу 54,1 проценттан 50,7 процентка кимеде.

2012 елның маенда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Doing Business рейтингында 2015 елда илнең позициясен 50 нче урынга, ә 2018 елда 20 нче урынга күтәрергә дигән бурыч куелды.

Бөтендөнья Банкының *«Россиядә бизнес алып бару – 2012»* докладында билгеләнгәнчә, бизнес алып баруның җиңеллеге буенча Казан бишенче урынга чыкты.

Бөтендөнья Банкының *«Россиядә бизнес алып бару – 2012»* тикшеренүендә 30 шәһәр: Воронеж, Иркутск, Казан, Мәскәү, Пермь, Петрозаводск, Ростова-на-Дону, Санкт-Петербург, Томск, Тверь, Владивосток, Владикавказ, Волгоград, Выборг, Екатеринбург, Калининград, Калуга,

Кемерово, Киров, Мурманск, Новосибирск, Омск, Самара, Саранск, Ставрополь, Сургут, Ульяновск, Хабаровск, Якутск һәм Ярославль шәһәрләре катнашты.

Бөтендөнья банкы тикшеренүендә предприятиеләрне теркәү, төзелешкә рөхсәт алу, электр тәэминаты системасына тоташу һәм милекне теркәү мәсьәләләренә чагыштырмача анализ ясалды. «Предприятиеләрне теркәү» процедурасы рейтингында Казан 4 нче урынны, «Төзелешкә рөхсәт алу» процедурасы буенча 14 нче урынны, «Электр тәэминаты системасына тоташу» процедурасы буенча 17 нче урынны, «Милекне теркәү» процедурасы буенча 4 урынны алды.

Төбәкләрдә бизнес климатны яхшырту факторлары күпчелектә дәүләт тарафыннан уздырылган эшкуарлыкны үстерү сәясәтенә бәйле. Административ киртәләрне киметү, законнарны, суд системасын, ярдәм итү механизмнарын камилләштерү, конкурентлыкны үстерү һәм башкалар бизнес алып бару өчен уңай шартлар булдыруга һәм инвестицияләр җәлеп итүгә булышлык итә.

Төбәкләрдә бизнес алып бару шартлары гомумроссиядәге тенденцияләрне исәпкә алып формалаштырыла.

2011–2013 елларда Татарстан Республикасында эшкуарлыкны үстерү белән идарә итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 декабрендәге 1151 номерлы карары белән расланган 2011–2013 елларда Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү республика программасы кысаларында алып барылды. Программаның төп бурычларыннан берсе булып инновацияле икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшкуарлыкның нәтиҗәле эшләве һәм аларны үстерү өчен шартлар тудыру, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүдә аның өлешен арттыру тора.

Программа чараларын гамәлгә ашыру тулай төбәк продуктында кече һәм урта бизнес өлешен арттыруга, эшкуарлык эшчәнлегенең икътисади актив субъектлары санын һәм аларның әйләнешен, аларда эшләүчеләр санын арттыруга этәргеч бирергә тиеш.

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый монитринг комитеты мәгълүматларына караганда, 2013 елда Татарстан Республикасында икътисадый актив 49 617 кече һәм 478 урта предприятие эшчәнлек алып барган. 2014 елның 1 гыйнварына шәхси эшкуарларның саны 90 556 га җиткән.

Икътисадый актив кече предприятиеләр саны 2013 елгы мәгълүматларга караганда 2012 ел күрсәткечләре белән чагыштырганда 1 717 берәмлеккә арткан. Икътисадый актив кече предприятиеләрнең уртача үсеш темпы (2011-2013 елларда) 6 проценттан чак артык.

Урта предприятиеләр һәм шәхси эшкуарларга килгәндә, биредә тискәре динамика күзәтелә.

2011 елдан 2013 елга кадәр урта предприятиеләр саны 280 берәмлектән артып киткән. Өч ел эчендә (2011-2013) урта предприятиеләр саны уртача 14 процентка кимегән.

Шәхси эшкуарлар саны кискен кимүгә аерым тукталырга кирәк. Әйтик, 2013 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 1 гыйнварына кадәр 20 400гә якын эшкуар үз эшчәнлеген туктаткан.

«Авыл эшкуарларында» да шушындый ук хәл күзәтелә. Соңгы өч ел эчендә КФХ башлыклары саны тиз кими бара. 2010 елда Татарстан Республикасында 19 245 КФХ башлыгы теркәлгән, 2013 елда аларның саны 5 меңгә калды. Шул рәвешчә, өч ел эчендә 14 мең КФХ башлыгы эшләүдән туктаган. 2013 елда сакланып калган 5 112 КФХ башлыгының яртысы гына законнарда каралган тәртиптә теркәлгән җир кишәрлегенә ия (Росреестр мәгълүматлары буенча).

**Административ киртәләр**

2013 елдагы эш йомгаклары бюрократия басымы көчле булу элеккечә үк зур проблема булып торуын күрсәтте. Эшкуарлык эшчәнлеге барышында эшкуарлар аеруча киң таралган административ процедураларны узганда кыенлыкларга очрыйлар. Алар арасында җир кишәрлеге алу, төзелешкә рөхсәт алу һәм объектны эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт алу, электр тәэминаты челтәрләренә тоташу һәм башкалар бар.

Икътисадның кайбер тармакларында дәүләт җайга салуының артык яисә нәтиҗәсез административ механизмнарны альтернатив базар механизмнары белән алыштыру мәсьәләсе дә гаять мөһим. Биредә сүз федераль башкарма хакимият органнары (аларга буйсынган оешмалар) тарафыннан гына башкарыла торган экспертизалар исемлеген киметү, экспертизалар уздыру эшчәнлегенә дәүләтнеке булмаган оешмаларга рөхсәт бирү турында бара.

Эшкуарларның хисап бирүләре нәтиҗәсендә туган чыгымнарын киметү, шулай ук кече һәм урта эшкуарларга бу юнәлештә аерым преференцияләр бирү мәсьәләләре дә әһәмияткә ия.

Күп кенә процедуралар буенча эшкуарлар вакытлы һәм зур финанс чыгымнары белән бәйле кыенлыклар кичерәләр. Бу беренче нәүбәттә җир кишәрлеге алу һәм энергия тәэминаты челтәрләренә тоташуга кагыла. Болар башка процедураларга караганда аеруча күп вакыт һәм акча сарыф итүне таләп итә.

Җир һәм милек мәсьәләләре эшкуарның агымдагы эшчәнлегенә йогынты ясау күзлегеннән караганда аеруча четерекле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Язма мөрәҗәгатьләрне анализлау йомгаклары нәкъ шул турыда сөйли. Алар нәкъ менә шушы өлкәнең аеруча проблемалы булуын күрсәтәләр (мөрәҗәгатьләр саны 25,5 процентны тәшкил итә).

Төзелешкә һәм электр тәэминаты челтәрләренә тоташу өчен рөхсәт алуның кыенлыгы Бөтендөнья Банкы докладындагы рейтинглар белән раслана. Казан анда «Төзелешкә рөхсәт алу» һәм «Электр тәэминаты системасына тоташу» процедуралары буенча тикшерелә торган 30 шәһәр арасында тиешенчә 17 нче һәм 14 нче урыннарда тора. Шушы ук проблемаларны эшкуарлар да атадылар.

Күп кенә мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән адымнар АСИ милли эшкуарлык инициативасы кысаларында гамәлгә ашырылучы юл карталарында чагылыш тапты.

Шуңа да карамастан, бу проблемалар бик кискен тора һәм эшкуарларның үсешен тоткарлый.

## Финанслауның мөмкин булуы – дәүләт (финанс) ярдәме

Финанслар белән тәэмин ителү эшкуарларның иң төп проблемаларыннан берсе булып тора.

2013 елда эшкуарлар финанслар белән тәэмин ителү мәсьәләләрен, шулай ук дәүләт ярдәме чараларының нәтиҗәлелеген проблема буларак күрсәттеләр.

Кече һәм урта эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтү системасына федераль министрлыклар белән берлектә һәм фәкать Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган төрле программалар комплексы керә. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча аерым программалар «дәүләт банклары» тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2013 елда финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру буенча, 808 кече һәм урта эшкуарлык субъекты субсидияләр алды. Күрсәтелгән ярдәмнең гомуми суммасы 818 398 мең сум тәшкил итте. 375

кече һәм урта эшкуарлык субъектының ярдәм бирү турындагы үтенече кире кагылды.

Авыл хуҗалы продукциясе җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме күрсәтү барышында 2013 елда Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына 28 юнәлештә дәүләт ярдәме күрсәтелде. Бирелгән субсидияләрнең (грантларның) гомуми суммасы 15,5 млрд. сум тәшкил итте.

Гаилә терлекчелек фермаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында сөйләгәндә, 270 фермерга ярдәм күрсәтелүен, 2013 елда республика бюджетыннан гомуми ярдәм суммасының 200 953 мең сум тәшкил итүен әйтеп китәргә кирәк.

Эшкуарлар күрсәтелә торган дәүләт (финанс) ярдәменең бик аз һәм кайбер очракларда нәтиҗәсез булуыннан зарланалар. Грант яисә субсидия рәвешендә бирелгән әлеге ярдәмнең аерым төрләре проектка кирәкле финанс ярдәменең 10-15 процентын капларга да чак кына җитә. Башка финанс чыганаклары булмаган проект яшәүдән туктый. Дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтелгән проектларның нәтиҗәлелегенә мониторинг уздыру системасы булмавын билгеләп китәргә кирәк.

Эшкуарлар дәүләт (финанс) ярдәме алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү кыен булуыннан зарланалар. Башкарма хакимиятнең һәр органы ярдәмнең һәрбер формасына финанс ярдәме күрсәтүгә гарызнамәләр бирүнең һәм аларны карап тикшерүнең «үз» кагыйдәләрен эшли. Эшкуарлар төрле дәүләт органнарыннан белешмәләр һәм төрле күчермәләрдән торган тау-тау гарызнамәләр китерергә мәҗбүр булалар (ә бит республикада 2012 елдан тармакара электрон хезмәттәшлек системасы бар, әмма эшкуарлыкка ярдәм чаралары күрсәткәндә ул эшләми). Күп кенә эшкуарлар республиканың башка районнарыннан Казанга килеп йөрергә мәҗбүрләр.

Коммерциячел кредитларга килгәндә, 2013 елда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кредит ярдәме күрсәтүдә банклар актив эшләүләрен дәвам иттеләр.

2013 елда республиканың кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шәхси эшкуарларны да кертеп, бирелгән яңа кредитларның тулаем күләме 53,1 млрд. сумга, ягъни 1,3 тапкыр артты, һәм 238,2 млрд. сум тәшкил итте, шуларның 21,4 млрд. сумы – шәхси эшкуарларга бирелгән кредитлар, бу – 2013 елда республиканың кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелгән кредитларның гомуми санының 9 проценты.

Татарстанның кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләренең, шәхси

эшкуарларны да кертеп, банкаларга гомуми бурычлары 8,4процентка яисә 10,5 млрд. сумга артты һәм 135,2 млрд. сум тәшкил итте, шуларның 5,1 млрд. сумы яисә 3,7 проценты вакытында түләнмәгән бурычлар булып тора.

135,2 млрд. сум бурычның 19, 3 млрд. сумы шәхси эшкуарлар өлешенә туры килә, бу 14,3 % тәшкил итә. Шәхси эшкуарларның банкларга вакытында түләнмәгән бурычлары 1,048 млрд. сум яки 5,4% тәшкил итә.

Кече һәм урта бизнеска бирелгән кредитларның юридик затларга яңа бирелгән кредитларның гомуми күләменә чагыштырганда бүгенге көндә 32,0%, бу исә бер ел элек булган күрсәткеч дәрәҗәсендә.

Кече һәм урта бизнеска бирелгән кредитларның гомуми күләменә чагыштырганда шәхси эшкуарларга бирелгән кредитлар өлеше ел буена 12,2 процenttан 14,3 процентка кадәр үсте, ә бирелгән кредитлар күләме 21,4 млрд. сум тәшкил итте.

Әгәр дә 2013 елда күрсәтелгән дәүләт (финанс) ярдәме күләмен кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шәхси эшкуарларны да кертеп, бирелгән кредитларның күләме белән чагыштырсак, 2013 елда ул якынча бәяләүләр буенча 6 процenttан чак кына артып киткән.

Дәүләт (финанс) ярдәме күрсәтелү, шулай ук кредитлар бирү үсүгә карамастан, бүген акча кытлыгы эшкуарлар өчен иң төп проблема булып тора. Банк кредитларыннан файдалану мөмкинлеге булмаган, эшчәнлеген башлап кына җибәргән предприятиеләр һәм микропредприятиеләргә финанс ярдәме күрсәтүдә зур кыенлыклар булуы билгеләп үтелә.

**Инфраструктура ягыннан һәм мәгълүмати ярдәм**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2013 елда бизнес үсеше өчен «югары уңайлылык» шартларын 1000 эшкуарлык эшчәнлеге субъекты урнашкан егерме икедән артык төп мәйданчык тәэмин итте. Төп мәйданчыклар арасыннан түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин: «КИП «Мастер» ААҖ, ИТ – парк (Казан һәм Чаллы шәһәрләре территорияләрендә), «Химград» технополисы, Татарстан Республикасы Агросәнәгать паркы, Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары, Бизнес-инкубаторлар һ.б.

Әлеге мәйданчыкларда ярдәм күрсәтү җитештерү һәм (яки) офис биналарына ташламалы аренда ставкасы билгеләү, консультация ярдәме күрсәтү, мәйданчыклар резидентлары товарларын (эш һәм хезмәт күрсәтүләрне) үткәрү рәвешендә күрсәтелә.

Эшкуарлар әйткәнчә, кече компанияләргә күрсәтелә торган консультация, маркетинг һәм башка хезмәтләрдән файда зур түгел. Аерым

очракларда мәйданчыкларда урнаштыру өчен эшкуарлар «арадашчы фирмалар» яисә «элемтәләр» хезмәтеннән кулланалар.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, инновация инфраструктурасының әлеге объектлары, урнаштыру шартлары һәм башкалар турындагы ачык чыганаклардагы мәгълүматның туплап бирелмәве аркасында, эшкуарлар өчен аннан файдалану авыр.

Ярдәм күрсәтү инфраструктурасының күп оешмалардан торуы эшкуарлар өчен билгеле бер кыенлыклар тудыра, чөнки тулы мәгълүматны бер урыннан гына алу мөмкинлеге бирми.

Башкача әйткәндә, эшкуар теләсә кайсы технопаркта, технополиста, бизнес-инкубаторда, сәнәгать мәйданчыкларында урнашуның шартларын һәм өстенлекләрен белә, резидентлар мәйданчыкларны үстерү буенча тәкъдимнәр бирә һәм хезмәткәрләрен эшен бәяли ала, ә эшкуарлар үзләре һәркем куллана алырлык итеп үз эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге турында хисап урнаштыра ала торган бердәм мәгълүмати мәйданчык юк.

Чынлыкта бүген **республикада эшкуар бизнесны үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтүгә кагылышлы барлык зарури мәгълүматны алырлык бердәм платформа булдырылмаган**. Татарстан Республикасында инвестиция порталы булдырылган, әмма әлеге ресурстан, эшкуарлар фикеренчә, кирәкле мәгълүмат алып булмый.

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге өчен нигездә уңай шартлар тудырылган. Шул ук вакытта, бюрократик киртәләр элеккечә үк эшкә тоткарлык ясый. 2014 елда эшкуарлар өчен административ киртәләрне киметү һәм төзелеш, энергетика, милекне һәм бизнесны теркәү өлкәсендә инвесторларга кирәкле хезмәтләрнең бәясен һәм аларны күрсәтү срокларын киметү юнәлешендә эшне дәвам итәргә кирәк. Кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме күрсәтүнең гамәлдәге төрләре, һичшиксез, Татарстан Республикасында эшкуарлыкның үсешенә саллы өлеш булып тора, әмма аларның нәтиҗәлелеген күтәрергә кирәк.

Дәүләт (финанс) ярдәме күрсәтүне гадиләштерү өчен аларны күрсәтүнең шартларын стандартлаштыру зарури. Эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары өчен эшкуарларга ярдәм күрсәтүнең интерактив чаралары булган эшләүче мәйданчык (системалар һәм сайтлар, шул исәптән муниципаль, интеграцияләнгән платформа) булдырырга кирәк. Биредә теләсә кайсы бизнесмен үз компаниясен үстерү мөмкинлекләре, яңа ысуллар һәм технологияләр, хезмәткәрләрнең квалификациясен үстерү, эшчәнлек алып баруда нинди куркынычлар килеп чыгарга мөмкин булуын тиз һәм

ансат белешә, турыдан-туры элемтәләр һәм фонд, компания яисә ул үз предприятиесен үстерү проектын бергәләп финанслау мөмкинлеге бирә торган программа турында кирәкле мәгълүмат ала алсын.

Мәгълүмати мәйданчык базасында эшкуарлыкка дәүләт (финанс) ярдәме күрсәтү чараларын координацияләү һәм мониторинглауның бердәй системасын гамәлгә ашыру максатка яраклы булачак. Анда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм чарасының теләсә кайсысына туры килә торган стандарт документлар пакеты белән гарызнамә бирү, шунда ук проектны карап тикшерү йомгаклары турында мәгълүмат алу һәм аны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча акчаны максатчан сарыф итү турында хисап бирү мөмкинлеге тәэмин ителсен.

Әлеге система эшкуарга «бер тәрәзә» режимында дәүләт ярдәменең гамәлгә ашырыла торган барлык чаралары турында мәгълүмат алырга, бизнесын үстерү ихтыяжларына иң яхшы туры килүче программалар буенча гарызнамә бирергә мөмкинлек тудырачак.

Бу система республика җитәкчелегенә «онлайн» режимында эшкуарларга ярдәм күрсәтүнең гамәлгә ашырыла торган чаралары нәтиҗәлелеге, аларны гамәлгә ашыруда катнашучы чиновникларның эшчәнлеге турында объектив һәм тулы мәгълүмат алу, инвестиция мөмкинлекләрен ачыклау, проблемаларны аңлау мөмкинлеге бирәчәк.

Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына инфраструктура ярдәме күрсәтү буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар күрергә кирәк.

Бизнесның уңышлы баруы хокукый, бухгалтерлык, салым салу юнәлешләрендә алып барылган эш сыйфатыннан һәм интеллектуаль милек объектларына хокукның ни дәрәҗәдә якланган булуыннан тора. Эшкуарларга ерактан торып ярдәм күрсәтүне һәм урыннарда резидентлар белән эшләүче белгечләрнең квалификациясен тикшерүне тәэмин итә торган бердәм консультатив үзәк булдыру эшкуарларга күрсәтелә торган консультация ярдәменә чыгымнарны киметүне һәм аларның сыйфатын тәэмин итәчәк.

Эшкуарлыкны үстерүдә эшкуарларга җирле үзидарә органнары күрсәткән ярдәм аеруча зур әһәмияткә ия. Җирле үзидарә органнарының төп бурычларыннан берсе булып эшкуарлыкны үстерүгә уңай климат һәм аңа төрле чаралар белән ярдәм күрсәтү тора.

Республика җирле үзидарә органнарын кече эшкуарлыкны үстерү эшчәнлегендә кызыксындыруга юнәлтелгән эшне көчәйтергә кирәк. Аерым алганда, эшкуарлыкны үстерү буенча шәһәр округлары һәм муниципаль

районнар җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре системасын булдырырга кирәк.

## ЭШКУАРЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ СУБЪЕКТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЫЙ ХӘЛЕН КАМИЛЛӘШТЕРҮ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР

Вәкаләтле вәкил алдында торган төп бурычларның берсе – эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча мәгълүмат туплау, аны өйрәнү һәм анализлау. Әлеге бурычны үтәү өчен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы хокукый актлар (норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү яисә аларны үз көчләрен югалткан дип тану турында) нигезләнгән тәкъдимнәр юллау хокукы бирелгән.

Куелган бурычларны үтәү өчен, үзенең булган вәкаләтләренә таянып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукый хәлен камилләштерү турындагы түбәндәге тәкъдимнәрне кертә.

### 1. Татарстан Республикасында шәхси эшкуарлар өчен салым салуның патент системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр

2013 ел дәвамында гамәлдәге законнарның салым салуның патент системасын куллану тәртибен регламентлаштыручы нигезләмәләренә үзгәрешләр кертү зарурлыгы турындагы мәсьәләләр буенча фикер алышу барды. Хәзерге вакытта Вәкаләтле вәкил түбәндәге тәкъдимнәр алды:

1) шәхси эшкуар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча алынган еллык керемнәрне алуга мөмкин булган күләмнәрен киметү ягына кабаттан карарга, шул ук вакытта патент бәясен эшкуарда эшләүчеләр санына турыдан туры бәйләмәскә;

2) патент бәясен эшкуарда эшләүче хезмәткәрләр санына бәйләп дифференциацияләгәндә дифференциациянең иң түбән баскычын билгеләргә. База керемнәре хезмәткәрләр саныннан аерымлы физик күрсәткечләргә бәйле рәвештә билгеләнә торган эшчәнлек төрләре өчен база керемнәре күләмен 2008 елда Татарстан Республикасы территориясендә патент нигезендә гадиләштерелгән салым салу системасын кертү барышында билгеләнгән эшчәнлек төрләре буенча база

керемнәре күләменә нигезләнеп билгеләргә. Шуның белән бергә, әлеге күрсәткечләрне 2009 – 2013 еллардагы инфляция ндекслары буенча үзгәртергә;

3) Казаннан аермалы буларак, торак пунктлар өчен база керемнәре күрсәткечләрен түбәнәйтүне күздә тотарга;

4) «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патентлы системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага Россия Федерациясе Салым кодексының 346.43 статьясының 2 пунктындагы 19, 45 – 47 пунктчаларында күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча эшкуар тарафыннан алынуы мөмкин булган еллык керем күләмен (арендага тапшыру, ваклап сату, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү) аерымланган объектлар санына бәйләп түгел, бәлки мәйданнарның күләменә карап билгеләргә;

5) Россия Федерациясе Салым кодексында Россия Федерациясе субъектларына аларга карата эшкуарлык алып бару урынына бәйле рәвештә патентлы салым салу системасы кулланыла торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча эшкуар тарафыннан алынуы мөмкин булган еллык керем күләмен дифференцияләргә мөмкинлек бирә торган норма булдырырга;

6) Россия Федерациясе Салым кодексында түбәндәгеләрне күздә тотарга:

- эшкуарлык эшчәнлеген алып бару урынында патент бирү;
- салым салу чорында индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең физик күрсәткеченә потенциаль алырга мөмкин булган еллык кереме күләмен исәпләгәндә файдаланыла торган, салым салуның патент системасы кулланылу белән бәйле салым арткан күрсәткечләрне файдаланып физик күрсәткеч арткан айдан соң килә торган айның 1 числосыннан исәпләнәчәк ;
- салым салуга патент системасын куллану хокукын югалтканда салым салуның бер үк вакытта гадиләштерелгән системасын кулланганда салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланырга; салым салуның патент системасы белән һәм авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр өчен салым салу системасын бер үк вакытта кулланганда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр өчен салым салу системасын куллану мөмкинлеге; салым салуның патент системасын һәм эшкуарлык эшчәнлегенең элегрәк патент алынган төре буенча керемгә бердәй салым рәвешендәге салым салу режимын кулланганда, һәм әгәр салым түләүче элегрәк патент алынган чорда керемгә бердәй салым түләүче сыйфатында исәпкә куелса, әлеге салымны түләүче сыйфатында исәпкә куелган датадан

керемгә бердәй салым рәвешендәге салым салу режимын куллану мөмкинлеге;

- патент системасын куллануга хокукын югалтканда, салым түләүчене салым салуның патент системасын куллану белән бәйле салым түләүдән азат итү.

Моннан тыш, салым салуның патент системасын кулланучы индивидуаль эшкуарларны иминият кертемнәрен түләүдән азат итү турында фикер алышулар бара.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясе Дәүләт думасында салым салуның патент системасын куллану тәртибен ачыклауга кагылышлы берничә закон проекты карала һәм салым органының федераль законнарга үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәре анда тикшерелә инде.

2014 елда «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ Законына үзгәрешләр кертү өчен ахыргы тәкъдимнәрне эшләү буенча эшне төгәлләү максатка яраклы булачак. Бу эшкә Татарстан Республикасының кызыксынган министрлыкларын һәм ведомстволарын, шулай ук эшкуарлар берлекләрен тарту кирәк. Әлеге эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тиешле закон проектын карауга кертү өчен тәкъдимнәр әзерләнәчәк.

## 2. **Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтү чараларына кагылышлы тәкъдимнәр**

Дәүләт ярдәме алучыларның бердәй автоматлаштырылган реестрын төзеп, эшкуарлыкка дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын күрсәтү шартларын анализлау һәм стандартлаштыру эшен уздырырга тәкъдим ителә. Әлеге эш кысаларында эшкуарлыкка дәүләт финанс ярдәме күрсәтүнең барлык программалары өчен гарызнамәләр кабул итүдә һәм хисаплылыкта «бер тәрәзә» системасын булдыру тәкъдим ителә. Моннан тыш, эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары өчен бердәм мәгълүмати мәйданчык булдыру мөмкинлеген карап тикшерү тәкъдим ителә. Анда теләсә кайсы бизнесмен үз компаниясен үстерү мөмкинлекләре, яңа ысуллар һәм технологияләр, хезмәткәрләрнең квалификациясен үстерү, эшчәнлек алып баруда нинди куркынычлар килеп чыгарга мөмкин булуын тиз һәм ансат белешә алсын, турыдан-туры элемтәләр һәм фонд, компаниясен яисә предприятиесен үстерү проектын

бергәләп финанслау мөмкинлеге бирә торган  программа турында кирәкле мәгълүмат урнаштырылсын.

Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына карата тикшерүләр һәм актларның бердәм реестрын булдырырга тәкъдим ителә.

3. **Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре әйләнешен активлаштыру буенча тәкъдимнәр**

4. Әлеге мәсьәлә буенча берьюлы берничә юнәлештә гамәл кылырга тәкъдим ителә:

1) Муниципаль берәмлекләр башлыкларына  кыска вакытларда судка файдаланылмаучы җир кишәрлекләренә милекчелек хокукын муниципаль берәмлекнеке дип тану, алга таба тиешле җир кишәрлекләренә муниципаль милек хокукын теркәү өчен документлар бирү таләпләрен кую эшен тәмамларга;

2) дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары  белән берлектә физик затларга җир өлешләре хисабына бирелгән, аларга карата хәзергә кадәр аларга тиешле җир кишәрлеге бүлеп бирү буенча эш тәмамланмаган аерымланган җир кишәрлекләре барлыкка килү белән бәйле вазгыятьне өйрәнергә. Җир кишәрлекләре исәбеннән җир кишәрлекләре бүлеп бирү процедурасын тизләтергә;

3) дәүләт һәм муниципаль хакимиятнең вәкаләтле органнарына кыска вакыт эчендә җир кишәрлекләрен кадастр исәбенә алуны һәм муниципаль һәм дәүләт милке  хокукын теркәүне төгәлләргә.

**4. Гаилә терлекчелек фермаларын төзүне (реконструкцияләүне) финанслауга чыгымнарны каплауга кагылышлы тәкъдимнәр**

Әлеге проблема  «Татарстан Республикасы эшкуарларының системалы проблемалары» бүлегендә яктыртылды инде.

Әлеге вазгыятьне хәл итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының гаилә терлекчелек фермаларын төзүгә (реконструкцияләүгә) чыгымнарын  каплауны бергәләп финанслау  буенча бурычларын үтәвен анализларга һәм муниципаль берәмлекләрнең ресурслары чикләнгәнлеге шартларында  әлеге хәлне хәл итүнең мөмкин булган юллары турында фикер алышырга.

5. **Кадастр хаталарын төзәткәндә чыгымнарны күтәрү тәртибен билгеләү буенча тәкъдимнәр**

«Күчемсез милек дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ Федераль закон белән кадастр хаталарын төзәтүгә бәйле чыгымнарны әгәр дә теге яисә бу кишәрлекне алуга кызыксыну белдергән затлар, аларга җир кишәрлеген бирү турындагы гариза биргәндә кадастр инженерларының яисә вәкаләтләр бирелгән затларның сорала торган җир кишәрлеге чикләре координаталарын билгеләүгә каршылык күрсәтүче органнарның җир кишәрлеге координаталары турында язмалар керткән вакытта хаталары ачыклану вазгыяте белән очрашканда җир кишәрлеге чикләрен төгәл билгеләү һәм кадастр инженеры хезмәтенә түләү җир кишәрлеген алуда кызыксынган гарызнамә бирүче хисабыннан түләнә. Шул ук вакытта, кайбер очракларда кадастр инженерларының хезмәтенә түләү шактый зур сумма тәшкил итә, бу исә җир кишәрлекләре бирү турында гамәлдәге законнарда каралмаган өстәмә чыгымнар тотылуын китереп чыгара.

Югарыда әйтелгәннәр белән бәйле рәвештә «Күчемсез милек дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ Федераль законга ачыкланган кадастр хаталарын төзәтү белән бәйле чыгымнарны җир кишәрлеген кадастр исәбенә куйганда хаталар җибәргән вәкаләтле органнарга (яисә аларның хокукый дәвамчыларына) күтәртү тәртибен билгеләүгә кагылышлы тәкъдимнәр кертү башлангычы максатка ярашлы була.

**6. Татарстан Республикасы эшкуарлары тарафыннан турыдан-туры әйтелгән һәм аларга игътибар ителергә тиешле өстәмә тәкъдимнәр :**

1) Эшкуарларда эшләүче хезмәткәрләргә югары социаль түләү дәүләт йөкләмәләре буенча һәм мәҗбүри финанс (бухгалтерлык) хисабын, мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча хисапны төзегәндә һәм биргәндә кыенлыклар туу белән бәйле проблемаларны хәл итү өчен түбәндәге тәкъдимнәр бирелде:

- кече һәм урта бизнес субъектлары эшчәнлегенең башлангыч чорында мәҗбүри социаль түләүләрне күчерү буенча бюджеттан субсидияләр бирү хисабына ташламалар бирергә;
- кече һәм урта бизнес субъектлары өчен мәҗбүри акча күчерүләрне киметү өлешендә законнарга тиешле үзгәрешләр кертергә;
- салым һәм бухгалтерлык хисаплылыгын гадиләштерергә, салымнар буенча салым базасын хисаплау процедурасын гадиләштерергә;
- мәҗбүри документлар әйләнешен киметергә;

- исәп алып баруны һәм хисаплылыкны тапшыруны электрон рәвештә алып бару системасын эшләргә;
- «бер тәрәзә» принцибын куллануны киңәйтергә;

Кирәгеннән артык салым контроле проблемасын хәл итү өчен түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

- салым түләүчеләр счетлары буенча операцияләрне вакытлыча туктатып торганда салым органнары гамәлләренә салым түләүчеләр шикаять бирүдә аерым тәртип урнаштырырга;
- югарырак торучы салым органы тарафыннан салым түләүчеләр счетлары буенча операцияләрне вакытлыча туктатып торганда салым органнары гамәлләренә бирелгән салым түләүчеләр шикаятьләрен карауны 10 көн белән чикләргә;
- салым түләүчеләр счетлары буенча операцияләрне вакытлыча туктатылуына бирелгән шикаятьләрне арбитраж судларында карауга 10 көн вакыт билгеләргә (судта административ хокук бозулар буенча эшләрне карауга тиңдәш);
- счетларны вакытлыча туктатып тору буенча гамәлләрне дөрес дип тапкан судларның карарлары кичектергесез үтәлергә тиеш дип табылган тәртип урнаштырырга, шул ук вакытта карарга шикаять бирү өчен бер ай вакыт турындагы нигезләмәне үзгәрешсез калдырырга (банкротлык турындагы эшләргә тиңдәш);
- счетлар буенча операцияләрне туктатып торуны вакытында бетермәгән салым органнары вазыйфаи затларына карата җинаять җаваплылыгы кертергә;
- салымнар турындагы законнарга салым органнары, Россия Федерациясендәге барлык судлар, хокук саклау органнары һәм әлбәттә салым түләүчеләрнең үзләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле «салымнан файда» дигән анык һәм конкрет төшенчә (термин) кертергә.

2) Җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең базар бәясенә туры килмәвен түбәндәгечә хәл итәргә:

- кадастр бәясе төшенчәсен алып ташлап, бары тик салым салына торган базаны билгеләү нигезе булып торачак базар бәясе төшенчәсен генә калдырып, норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертергә.

**2014 ЕЛГА БУРЫЧЛАР**

Вәкаләтле вәкилнең 2014 елга төп бурычы булып, 2013 елдагы кебек үк, эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, шулай ук аларның хокукларын торгызу тора. Вәкаләтле вәкил эшкуарлардан килгән мөрәҗәгатьләр белән оператив төстә һәм нәтиҗәле итеп эшләргә, системалы мәсьәләләрне ачыкларга, шулай ук әлеге системалы мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән тиешле тәкъдимнәр әзерләргә планлаштыра.

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 05 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясының 4 пункты нигезендә Вәкаләтле вәкил эшкуарлык эшчәнлегенә кагылышлы Татарстан Республикасы закон проектлары һәм башка норматив актлар проектлары әзерләүдә катнашырга, әлеге атап үтелгән проектларны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр әзерләргә хокуклы. Шулай итеп, эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары арасында яисә алар белән дәүләт арасында булган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив актлар проектлары кабул ителгәнчегә кадәр эшкуарларга ясаячак йогынтыны тикшерү өчен Вәкаләтле вәкил тарафыннан өйрәнелә.

Һәрбер бурычны аерым-аерым җентекләбрәк карап китик.

Беренчедән, Вәкаләтле вәкилнең эшкуарлардан килгән мөрәҗәгатьләрне оператив төстә һәм нәтиҗәле итеп карау бурычына килгәндә, шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2014 елда эшнең аеруча мөһим бер юнәлеше булып Казан һәм Чаллы шәһәрендә Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләрен оештыру тора. Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләрендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына түләүсез телдән һәм язмача консультацияләр биреләчәк, эшкуарлардан шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр кабул ителәчәк, шулай ук Вәкаләтле вәкил үзе караган мөрәҗәгатьләр буенча аннан килгән документларга экспертиза ясалачак.

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 05 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең язмача ризалыгы буенча, дәүләт контроле (күзәтчелеге) яисә муниципаль контроль кысаларында мөрәҗәгать итүчегә карата уздырылган тикшерүдә урынга барып

катнашырга хокуклы. Шулай итеп, 2014 елда дәүләт контроле (күзәтчелеге) яисә муниципаль контроль кысаларында эшкуарларга карата уздырылган тикшерүләрдә урынга барып катнашуларны оештыру планлаштырды.

Икенчедән, шуны да билгеләп үтү мөһим, 2014 елда Вәкаләтле вәкил берничә эш төркеме оештырырга планлаштырды, биредә республиканың эксперт, фәнни һәм эшкуарлык берләшмәләрен җәлеп итү юлы белән, 2013 елда ачыкланган һәм шулай ук Татарстан Республикасы эшкуарлыгына кагылышлы яңа системалы мәсьәләләр каралачак. Шулай итеп, Россия монополиягә каршы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә рекламага кагылышлы законнарны куллану мәсьәләләре һәм стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның хокукый регламентлары мәсьәләләре буенча ике эш төркеме булдыру планлаштырылды. Моннан тыш, министрлыклар һәм ведомстволар, экспертлар һәм эшкуарлык берләшмәләре вәкилләрен җәлеп итеп оештырылган икенче бер эшче төркем составында салым салуның патент системасын оптимальләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр формалаштыру буенча эш дәвам иттереләчәк. Әлеге эш төркеме кысаларында Россия Федерациясендә салым салуны җайга салу мәсьәләләре буенча эксперт берләшмәләреннән килгән тәкъдимнәрне тикшерү дә күздә тотыла.

Тиешле дәүләт органнары белән даими һәм оператив эшчәнлек алып баруны гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы эшкуарлыгының системалы мәсьәләләрен бергәләп ачыклау һәм тикшерү өчен мәйданчыклар булдыру максатларында, 2014 елда Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгы Идел буе төбәкара территориаль идарәсенең Татарстан Республикасындагы инспекциясе, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең (Ростехнадзор) Идел буе идарәсе, Россия Табигать күзәтчелеге хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Росреестрның Татарстан Республикасы буенча федераль кадастр палатасы, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасы Вәкаләтле вәкиллеге һәм башкалар белән үзара эшчәнлек һәм хезмәттәшлек турында килешүләргә кул кую планлаштырыла.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, бүгенге көндә Татарстан Республикасы эшкуарлыгының системалы мәсьәләләрен ачыклау һәм аларны чишү өчен тәкъдимнәр әзерләүдә муниципаль хакимият органнары катнашмый диярлек. Ә бит муниципаль органнар көн саен эшкуарлар белән турыдан-туры аралаша, һәм нәкъ менә муниципалитетларның вазыйфаи затлары конкрет муниципаль берәмлек территориясендә килеп туган иң мөһим һәм актуаль эшкуарлык проблемаларыннан хәбәрдар. Шул уңайдан, 2014 елда Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнары белән эшчәнлекне тагын да көчәйтергә һәм эшкуарлыкның системалы мәсьәләләре турында фикер алышуга аларны тагын да күбрәк җәлеп итәргә тели.

Ачыкланган системалы проблемаларны хәл итү кысаларында 2014 елда эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары өчен семинарлар уздыруны оештыру планлаштырыла. Мөмкин булган төп темалар арасында түбәндәгеләрне атарга мөмкин: финанс оешмалары белән үзира хезмәттәшлек вакытында эшкуарларның хокукларын яклау; эшкуарларның бөлгенлеккә төшү (банкротлык) процедураларын җайга салу һәм гамәлләр новеллары, хокуклар бозылуны бетерү, эшкуарларның кадастр, җир мөнәсәбәтләре һәм милек хокуклары өлкәсендә хокукларын бозылу очраклары белән эшләү, кече һәм урта бизнес өлкәсендә эшкуарлар хокукларын бозуны бетерү, эшкуарларның салым өлкәсендә хокуклары бозуны бетерү, эшкуарларның янгын куркынычсызлыгы, граждан оборонасы һәм халыкны гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда яклау өлкәсендә хокукларын яклау, эшкуарларның таможня өлкәсендә хокукларын бозуны бетерү, эшкуарларның законсыз җинаять эзәрлекләве белән бәйле хокуклары бозылуны бетерү.

Административ киртәләргә каршы көрәшү аерым блок булып тора. 2014 елда Стратегик инициативалар агентлыгының милли эшкуарлык инициативасы кысаларында эшләнгән һәм гамәлгә ашырылучы чараларның нәтиҗәлелеген бәяләү буенча эшне дәвам итү планлаштырыла. Төзелеш һәм электр энергетикасы өлкәсендә эшкуарлык мохитен яхшыртырга тиешле юл карталары нәтиҗәлелеген бәяләүгә игътибар биреләчәк: «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү һәм төзелеш өлкәсендә эшкуарлык мохитен яхшырту» һәм «Энергетика инфраструктурасыннан һәркем файдалана алуны арттыру».

Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгы,

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән берлектә эшкуарлар өчен административ киртәләрне киметүгә, төзелеш, энергетика, милек һәм бизнесны теркәүгә алу өлкәсендә инвесторларга кирәкле хезмәтләр күрсәтүнең бәяләрен һәм вакытын киметүгә юнәлтелгән эш оештырылачак.

Өченчедән, Вәкаләтле вәкилнең хокук куллану буенча гамәлләре турында сөйләгәндә, түбәндәгеләр турында әйтергә кирәк. 2013 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкилнең судка мөрәҗәгать итү буенча хокукын гамәлгә ашыру процедурасын законнар нигезендә регламентлаштыру процессы тәмамланды. 2014 елда Вәкаләтле вәкил, шундый ихтыяҗ туганда, әгәр Вәкаләтле вәкил тарафыннан дәгъваланучы норматив булмаган хокукый акт, карар, гамәл (гамәл кылмау) законга яисә башка норматив хокукый актка туры килми һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза, аларга законга каршы килә торган нинди дә булса бурычлар йөкли, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруда башка киртәләр тудыра дип табылса, норматив булмаган хокукый актларны гамәлдән чыккан дип тану, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль законнарда аерым дәүләт вәкаләтләре яисә башка вәкаләтләр бирелгән оешмалар, вазыйфаи затлар карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итү хокукыннан файдалану мөмкинлегенә ия була. Шул рәвешчә, 2014 елда эшкуар мөрәҗәгатендә күтәрелгән проблеманы хәл итү максатларында, әгәр дә хокукларны һәм законлы мәнфәгатьләрне торгызуның башка чаралары нәтиҗә бирмәсә, Вәкаләтле вәкилнең әлеге хокукын гамәлгә ашыру планлаштырыла.